ӨЗМИЧӘ ТҮЗӘСЕ

Кызыл китапка кергән гөмбә һәм үсемлекләргә кагылуның җәзасы каты булачак

> 6

ЯҢА СЕБЕРКЕ

Урам җыештыручыларны эшкә тикшереп кенә алачаклар

> 15

ТУФАН ИМАМЕТДИНОВ:

«Элеккеге иркен фикерләү рәвешенә кайтырга иде»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 49 (29016) | Җомга | 7 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

vk.com

СЫЗЛАВЫК

СӨТ БӘЯСЕ НИК ТӨШӘ?

Авылның иң авырткан һәм күңелгә тия торган җире. Сүзебез, әлбәттә инде, халыктан җыела торган сөт бәяләре турында бара. Ул һәрвакыт игътибар үзәгендә булды, чөнки терлек асрау халыкка азмы-күпме табыш китерә. Тик февральдән бәяләр кинәт һәм күпләп төшә башлады. Бер-ике ай эчендә хаклар кайбер районнарда хәтта 8 сумга кадәр түбән тәгәрәде. Кызганыч, белгечләр әйтүенчә, бу әле чик түгел. Моның артында нәрсә ята һәм чыгу юлы бармы?

> 5

Ишетми калмагыз

Быелгы республикакүләм ифтар 15 апрельдә узачак. «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында узасы чарада 11 мең кеше катнашыр дип көтелә. Авыз ачу вакыты җиткәнче Республикакүләм ифтарда катнашучыларны елдагыча мәдәни программа көтә. Моннан тыш концерт залында татар-мөселман традицияләрен чагылдыручы 3D форматындагы видеопрограмма тәкъдим ителәчәк. Бередә мөселман товарларыннан торган хәләл күргәзмә дә эшләячәк. 18 сәгать 49 минутта ифтарда катнашучылар, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга ияреп, җәмәгать белән ахшам намазын укыячак, аннары ифтар залына узачак. Аларны пылау, кипкән җиләк-җимеш, камыр ризыклары, тәм-томнар, су, төрле җиләк-җимешләр белән сыйларга җыеналар. Республикакүләм ифтарга билетларны хәзер үк алырга мөмкин. Моның өчен мәчетләргә, республика мөхтәсибәтләренә яки Татарстан Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Татарстанда битлек режимы бетерелде. Шул рәвешле хәзер республиканың медицина, белем бирү, социаль оешмаларына битлексез керергә рөхсәт ителә. Моннан тыш хастаханәдә дәваланган кешеләрнең якыннарын хәл белергә дә кертә башлаячаклар. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсеннән хәбәр итүләренчә, республикада бу елның унберенче атнасыннан бирле грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны кимү күзәтелә. Чикләүләрне бетерү әнә шуңа бәйле.

Республикада 30 меңләп кеше «Тотальный диктант» язарга ниятли. Быел әлеге чара 20 нче мәртәбә уздырыла. Диктантны Россиянең барлык төбәкләрендә дә 8 апрельдә язачаклар. «Тотальный диктант» ел саен уза һәм рус теле буенча белемне тикшереп карау, хаталарны анализлап, белгечләрдән киңәшләр ишетү мөмкинлеге бирә. «Әлеге акциядә катнашучыларның саны елдан-ел арта. Ул олысына да, кечесенә дә, төрледән-төрле һөнәр ияләренә дә кызыклы. Ә рус теленә, грамоталылыкка карата кызыксыну арту – бик мөһим нәрсә», – диде «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе Ирина Александровская.

Атна ахырында Татарстанда тотрыксыз һава торышы көтелә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы 15 градуска кадәр күтәрелсә, төнге сәгатьләрдә –7 градуска кадәр төшәргә мөмкин.
Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 8 апрельдә Татарстанда һава торышы әллә ни үзгәрмәячәк. Көндез +9...+14 градус, төнлә –6 градус. Якшәмбе – 9 апрельдә төньяк-көнчыгыштан секундына 11 метр тизлектә җил көтелә. Көндез һава температурасы +10...+15 градус, төнлә –2...–7 градус чикләрендә тирбәләчәк.
Инде хәбәр ителгәнчә, бу атна башында Казанда һава торышы ике көн рәттән рекорд куйды. Дүшәмбе – 3 апрельдә 1954 елгы рекорд (16,6 градус) челпәрәмә килеп, 16,7 градус җылы булды. Сишәмбе – 4 апрельдә һава температурасы бөтенләй дә +18 градуска кадәр күтәрелде.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

4 апрельдә Әлмәт районында быелгы алтынчы игезәкләр дөньяга килде. Бу хакта район башкарма комитетының ЗАГС идарәсендә хәбәр иттеләр. Рамилә белән Ильяс Миндубаевлар яңа туган сабыйларга Самат һәм Ләйсән дип исем кушканнар. Өйдә аларны Айдар һәм Салават абыйлары көтә. ЗАГС идарәсе белгечләре бәхетле ата-ананы икеләтә шатлык белән котладылар һәм балаларның беренче дәүләт документларын – туу турында таныклыкларны һәм Татарстан Республикасы Рәисенең котлау хатын тапшырдылар.
(«Әлмәт таңнары»)

Зәй

Татарстан Архив эше буенча дәүләт комитетының «Тарихта без эзлебез – Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы» шәҗәрә фестиваленең төбәк этабында тугыз районнан килгән гаиләләр чыгыш ясады. Бәйгедә Әгерҗедән – Матвеевлар, Актаныштан – Шиһаповлар, Алабугадан – Бусыгиннар, Менделеевскидан – Будниковлар, Минзәләдән – Дәүләткуловлар-Шәриповлар, Түбән Камадан – Гайнемөхәммәтовлар, Тукайдан – Әһлиевләр, Чаллыдан – Мөхәммәтдиновлар, Зәйдән Әхмәтҗановлар катнашты. Аларны комитет рәисе Гөлнара Габдрахманова һәм район башлыгы урынбасары Петр Уразайкин сәламләде. Төбәк бәйгесендә беренче урынны яулаган Әхмәтҗановлар республика этабында Зәй районы данын яклаячак.
(«Зәй офыклары»)

Кукмара

Атлас Булатов исемендәге паркта Кошлар бәйрәме үткәрелде. Анда сыерчык оялары кунаклары күргәзмә, кош ояларын ясау буенча мастер-класслар оештырылды. «Галактика» балалар иҗат үзәге җитәкчесе Лира Усмакованың сүзләренә караганда, күргәзмәдә районның 31 мәктәбеннән килгән укучылар катнашты. Шулай ук бәйрәмдә өч балалар бакчасы коллективы да бар иде. Анда барлыгы 250 сыерчык оясы тәкъдим ителде, ә 23 укучы мастер-класс күрсәтте. «Кошлар көне – балалар бакчалары, мәктәпләр өчен зур бәйрәм. Хәтта кызлар да әти-әниләре белән берлектә кош оялары ясап алып киләләр», – ди район мәгариф идарәсе җитәкчесе Илфат Әхмәдуллин.
(«Хезмәт даны»)

Әлки

Яңа Чаллы имам-хатыйбы Габделхак Бәдретдинов, балалар иҗат йорты бүлеге мөдире Резидә Җиһаншина һәм бу эштә үз ихтыярлары белән катнашучы берничә кеше «55+ яшьтәгеләр кулында – санлы технологияләр» проекты аша 328536 сум күләмендә грант отты. Татарстан Республикасының гражданлык җәмгыятен үстерү грантлары кысасында бирелгән акчага мөселман киемнәре, 3 компьютер, видеолар карау өчен цифрлы җайланмалар, җиһазлар сатып алынган. Шулай ук планшетлар да кайтартылган. Аларны куллануп, өлкәннәрне өйдә укыту мөмкин булачак.
(«Әлки хәбәрләре»)

ЭШЛЕКЛЕ АШХАБАД



tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстанга сәфәр кылды. Ашхабадта ул Төрекмәнстан Президенты Сердар Бердымөхәммәдов һәм Халк Мәсләхәте Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәдов белән очрашты.

Сердар Бердымөхәммәдов белән очрашуда хезмәттәшлекне киңәйтү мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Анда әйтелгәнчә, ике арадагы хезмәттәшлек өчен барлык мөмкинлекләр дә кулланылмый. Бүген Төрекмәнстанда Татарстанның машина төзелеше һәм нефть эшкәртү өлкәсендәге берничә зур компаниясе эшли. «Ислам дөньясы белән хезмәттәшлек Татарстанның тышкы икътисадый һәм халыкара эшчәнлегенең һәрвакыт әйдәп баручы юнәлешләренең берсе булды. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» форумы икътисадый хезмәттәшлекнең төп мәйданчыгы булып тора», – диде Рөстәм Миңнеханов һәм Төрекмәнстан делегациясен әлеге чарага чакырды.

Гурбангулы Бердымөхәммәдов исә Рөстәм Миңнехановка ике арадагы мөнәсәбәтләрне ныгытудагы эше өчен рәхмәтен җиткерде. «Без моңа зур әһәмият бирәбез. Безнең ике яклы мөнәсәбәтләр дә уңышлы үсә», – диде ул. Яклар нефть эзләү, газ ташу, энергетика һәм химия продукциясен китерү кебек юнәлешләрдә хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов санкцияләр шартларында Төрекмәнстанның Россия белән хезмәттәшлеге туктамыйча, хәтта артуын да билгеләп үтте, һәм монда Гурбангулы Бердымөхәммәдовның өлеше зур.

Рөстәм Миңнеханов Гурбангулы Бердымөхәммәдовны май аенда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумында катнашырга чакырды. Очрашудан соң алар бергәләп Төрекмәнстанда чыгарылган товарларның сәүдә-сәнәгать күргәзмәсен карады.

Сакчыллык өчен

Технологик бәйсезлек, энергияне сакчыл куллану һәм тармакта импортны алмаштыру. Башкалада узган энергия һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумында нәкъ шул хакта сөйләштеләр.

Узган ел республикада тулай төбәк продуктының энергия сыйдырышлылыгы 1,6 процентка кимегән. Бу хакта җыен кысасында узган «Татарстанда энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика Хөкүмәте утырышында әйттеләр. Аны Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин үткәрде. Утырышта катнашкан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, икътисад тармакларының күпчелегенең эше энергия нәтиҗәлелегенә турыдан-туры бәйле. Бу нисбәттән, Россия энергетика министрының беренче урынбасары Павел Сорокин энергетикага игътибар биргәне өчен Татарстанга рәхмәт белдерде.

Башкарылган һәм башкарыласы эшләр турында Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко сөйләде. Аның сүзләренә караганда, алдагы ел белән чагыштырганда, былтыр республикада продукция җитештерү күрсәткече 6 процентка арткан. Шул ук вакытта энергия ресурсларын куллану чагыштырмача азрак үскән. Әлеге күрсәткеч 4,3 процент тәшкил итә. Билгеле булганча, санкцияләр аркасында, республикада Зәй ГРЭСын яңарту эше туктап калды.

– Бу үзебездә җиһазлар һәм технологияләр җитештерүчеләр өчен үсеш мөмкинлеге булып тора. Без республика энергетика тармагының бәйсезлеген тәэмин итәргә тиеш, – дип, алда торган иң зур бурычны билгеләде Олег Коробченко.

Беренчел бурычлар арасында яңа куәтләрне сафка кертү, интеллектуаль исәп системаларын гамәлгә кертү, газ-мотор ягулыгы базарын үстерү дә бар.

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ БЕР АДЫМ

Кадрлар кытлыгын киметә, илнең технологик мөстәкыйльлеген тәэмин итә. Сүз – инженерлык мәктәпләре турында. Татарстанда алар өчәү булачак. Өчесе дә университетлар базасында эшләячәк.

Кичә Чаллыдагы IT парк мәйданчыгында алдынгы инженерлык мәктәпләре җитәкчеләре белән семинар-киңәшмә үтте. Киңәшмә эшендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия фән һәм югары белем министры Валерий Фальков катнашты.

Илнең технологик мөстәкыйльлеген торгызуга инженерлык мәктәпләре булышачак. Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында шуңа басым ясады.

– Россия Президенты илнең технологик суверенитетын торгызу бурычын куйды. Инженерлык мәктәпләрендә белем бирүнең яңа сыйфаты һәм технологик эшләнмәләрнең яңа дәрәҗәсе ята. Бу – стратегик максатка ирешүнең төп ысулларының берсе, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан, Татарстанда андый мәктәпләр өчәү булачак. Алар КФУ, КНИТУ һәм Иннополис университеты базасында төзеләчәк.

Фән һәм тикшеренүләргә, эшләнмәләр уйлап табуга яшьләрне җәлеп итү эше алып барыла. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Татарстанда яшь галимнәр саны Россия буенча уртача күрсәткечтән артып китә. Кадрлар мәсьәләсеннән тыш, фән-мәгариф комплексының матди-техник базасын яңарту эшенә дә алып барылуын искәртте Рәис.

Рөстәм Миңнеханов «авырткан җир»не дә күрсәтте. Аныңча, бизнесның инновацияләргә һәм илдә уйлап табылган эшләнмәләргә кызыксынуы аз. «Бу проблема фәнни эшчәнлек нәтиҗәләрен патентлау стадиясендә дә, башка этапларда да күренә. Шул ук вакытта искәрмәләр дә бар. Алар арасында күп еллар дәвамында инновацияләр һәм югары уку йортлары белән берлектә гамәлгә ашырыла торган проектлар саны буенча лидерлардан саналган «КАМАЗ» һәм «Татнефть» компанияләре бар», – диде Рәис.

Инженерлык мәктәпләре турында сөйләшүгә әйләнеп кайтсак, аның әһәмиятен автокала җитәкчесе Наил Мәһдиев тә яхшы аңлый. «Бу проект кадрлар әзерләү һәм аларны шәһәрдә калдыру мәсьәләсен хәл итәчәк. Без яшьләрне шәһәрдә калдыру яклы. Алар бирелә сыйфатлы инженерлык белемен алсын иде. 5 ел элек Чаллыда яшәүчеләрнең 15 проценты гына бу юнәлештә белем алу турында уйласа, хәзер бу күрсәткеч 23 проценттан артык», – ди мэр.

Рәис сүзләренчә, республиканың алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү җәһәтеннән өстенлеге бар. Ул да булса – аның сәнәгый һәм фәнни-техник потенциалы. «Татарстан – эре сәнәгать үзәге. Әмма алдынгы инженерлык мәктәпләре булмаса, без республикабызның алга таба үсешен күрмибез», – дип ассызыклады ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, югары уку йортларындагы фәнне индустриаль хезмәттәшләр белән якынайтырга кирәк. «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү – конкрет нәтиҗәләргә ирешү өчен иң кыска юл. Бигрәк тә монарчы күрелмәгән санкцияләргә бәйле бүгенге чынбарлыгыбызны исәпкә алсак», – дип тә өстәде республика Рәисе.

Министр Валерий Фальков та Татарстан җитәкчесенең сүзләрен куәтләде. Аның әйтүенчә, Татарстанда фән һәм фәнни-технологик үсеш өстенлекле юнәлешләрнең берсе буларак карала. Ул Рөстәм Миңнехановка инженерлык мәктәбен үстерү проектына булган кызыксынуы өчен рәхмәтен дә җиткерде.

БЕЗНЕҢ ШӘРӘФИ

Талантлы щепкинчы, зыялы шәхес, меңләгән тамашачылар күңелендә мәхәббәт уяткан, Әҗәлгә дә гашыйк иттергән сәхнә остасы. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия драма театры легендасы Равил Шәрәфиевкә 85 яшь тулды. Юбилей кичәсен ул хезмәттәшләре һәм яраткан тамашачысы белән бәйрәм итте.

Аның тирәсендә һәрвакыт җанлылык, мәзәк, көлке булыр. 3 сәгатькә сузылган юбилей чарасы да чын мәгънәсендә сәнгать, иҗат, сатира кичәсе булды. Тамашачы аны аягүрә басып каршылады һәм озак алкышлады. Артистны котларга хезмәттәшләре, якыннары, дуслары җыелган иде. Котлаулар, шаярулар, җырлар, кызыклы һәм уйланырлык мизгелләр, Равил Шәрәфиевнең үзенең хатирәләре һәм аның турында истәлекләр. Легендар артистның юбилей кичәсе әнә шундый рухта узды.

Равил Шәрәфиевне юбилее белән котларга Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә килгән иде.

– 1954 елда без Равил белән икәү авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә йөри идек. Мин үттем, Равил узмыйча калды. Шул вакытта мин дә аның белән китсәм, хәзер берәр танылган артист булыр идем, – дип шаяртты Минтимер Шәймиев. – Равил Шәрәфиев – талантлы артист, сәхнә остасы, күпкырлы шәхес, һәр нәрсәдә үз фикере һәм үз позициясе булган кеше. Шундый артист, шундый шәхесләр булырга тиеш. Алар ничек фикер йөртә, тормышның катлаулы сорауларына ничек җавап бирә? Тормыш бит катлаулы. Синең ул яктан үз фикерең, үз кыйблаң бар. Бөтен халкыбыз ярата торган шәхесләребез булу – тамашачыларыбыз өчен бик зур бәхет. Сез – данлыклы, халыкка тәрбия бирә торган кешеләр. Халык сезне күбрәк тыңлый. Минем сезгә халык исеменнән баш иеп рәхмәт әйтәсем килә. Синең уен безне шатландыра, йөрәкләргә үтеп керә. Халык сине ярата, кадерли һәм хөрмәт итә. Бу – тамашачылар өчен дә, артист өчен дә зур бәхет.

Җылы сүзләрдән соң Дәүләт Киңәшчесе, Равил Шәрәфиевне котлап, «Эх, алмагачлары» җырын башкарды һәм артистка татар театры сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен Дуслык орденын тапшырды.

Равил Шәрәфиев үзенең коллегаларына, барлык тамашачыларга җылы тәбрикләүләре һәм театр сәнгатенә булган мәхәббәте өчен рәхмәт белдерде.



«Татар-информ»

– Бу юлы сәхнәгә нәрсәгә атланып чыгар икән, дип көлештеләр. Үз аягың белән чыгуга җитми икән. Бөтен труппага рәхмәт әйтәсем килә. Яшьләребез шулхәтле әйбәт. Мин алар алдында баш иям. Сәхнәгә атлап чыгарлык аягыннан һәм аннан вакытында чыгып китә белгән акылдан аермасын, – диде халык артисты.

Ләйсән САФИНА

КУШЫП ТОРАСЫ ДА ЮК

14 миллион сумлык 148 тонна гуманитар йөк. Республиканың «Яшь гвардия» хәрәкәте яшьләре «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге белән берлектә Луганск һәм Донецк Халык Республикаларына әнә шуның кадәр ярдәм җыйган.

«Бердәм Россия»нең Яшь гвардиясе» төбәк бүлеге җитәкчесе Динар Бариев сүзләренә караганда, 21 февральдә алар партиянең төбәк бүлеге белән берлектә #БезБергә штабын булдырган.

– Активистлар ярдәме белән анда халыкка иң кирәкле әйберләр, озак саклана торган азык-төлек җыелды. Шул рәвешле Луганск һәм Донецк Халык республикаларына барлыгы 14 миллион сумлык 148 тонна гуманитар йөк озатылды. Бу эштә 500ләп волонтер катнашты. Алар көчләрен дә, вакытларын да кызганмый, әле бүген дә актив рәвештә эшлиләр, – дип сөйләде ул хәрәкәтнең XIV сайлау-хисап конференциясендә.

Республикада коронавирус котырган пандемия чорында да, сайлаулар вакытында да «Яшь гвардия» вәкилләре бик актив булды. Бүген хәрәкәтнең һәр районда да бүлекчәләре бар. Җиде ел эчендә егетләр-кызлар 6,3 миллион сумлык грант откан.

– Төрле юнәлештә эш алып барабыз. Безнең егетләр экологик акцияләр уздыра, өмәләрдә актив катнаша. Яшьләрдә ватанпәрвәрлек тәрбияләү юнәлешендә дә зур эш алып барыла. Тарихи хәтерне саклау максатыннан «Иске Казан» проектын эшләдек. Аның нәтиҗәсе буларак, Казандагы һәр тукталышта башкала тарихы чагылган элмә такталар пәйда булды. Ел саен Җиңү паркында уздырылган «Җиңү шәме» акциясе дә шул максатны күздә тота, – ди Динар Бариев.

Конференциядә катнашкан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Яшь гвардия» вәкилләренә яшьтәшләре арасында аңлату эшләре алып барырга кирәклеген дә искәртте. Парламент башлыгы фикеренчә, килеп туган вазгыятьтә дус булмаган илләрнең яшьләребезнең башын бутарга маташулары да бик мөмкин.

Фәрит Мөхәммәтшин республикада «Яшь гвардия» хәрәкәтенә нигез салынганнан бирле әйләнә-тирәлекне саклау, ватанпәрвәрлек кебек мөһим юнәлешләрдә бик зур проектлар тормышка ашырылуын да билгеләп үтте. Парламент башлыгы яңа территорияләргә, бигрәк тә Татарстан шефлыкка алган Лисичанск шәһәренә гуманитар ярдәм җибәрүне хәзерге катлаулы вазгыятьтә башкарылучы иң мөһим эшләрнең берсе дип атады.

– Алар бу ярдәмне зур өметләр белән көтә. Ник дигәндә, безнең республикадан һәрчак кием-салым, дару, азык-төлек кебек иң кирәкле әйберләр килә. Күпмилләтле Татарстан халкының, бигрәк тә яшьләрнең кеше кайгысына битараф калмавына, һәрчак ярдәм итәргә әзер торуына сокланам. «Бердәм Россия»нең Яшь гвардиясе» төбәк бүлеге активистлары эшләгән #БезБергә штабының бу изге эшкә керткән өлеше әйтеп бетергесез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Татарстан яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков республикада яшьләргә үсәр өчен барлык мөмкинлекләр барлыгын искәртте.

– Теләсә кайсы оешмага үсештә булырга кирәк. Татарстандагы «Яшь гвардия» хәрәкәте дә алга барырга тиеш. Форсаттан файдаланып, шуны да искәртәсем килә: республикада инде икенче ел рәттән яшьләр сәясәтен тормышка ашырган оешмалар арасында социаль әһәмиятле проектлар бәйгесе уздырыла. Аның гомуми фонды 50 миллион сум тәшкил итә, – дип белдерде министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Хәерле сәгатьтә!

Республикада тулы куәтенә язгы кыр эшләре гөрли. Соңгы мәгълүматлар буенча, уҗым культуралары һәм күпьеллык үләннәр планлаштырылган мәйданның 33 процентында тукландырылган. Әтнә, Балтач һәм Кама Тамагыннан кала, барлык районнар тырмага чыккан. Бу хакта журналистларга республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Наил Залаков хәбәр итте.

– Быел яз 17–25 көнгә иртәрәк килде. Башка еллар белән чагыштырганда, март 4–6 градуска җылырак булды. Басулар өлгерә. Инде Нурлат, Азнакай, Актаныш, Зәй, Чирмешән, Аксубай, Буа районнары игенчеләре арпа чәчүгә кереште. Һәм андый районнар саны артып тора. 1 мең гектарга чәчелгән. Әлегә һава торышы бик уңай. Чәчүне кыска вакыт эчендә башкарып чыгырга тырышабыз, – диде ул.

Язгы культуралар 1,8 млн гектарга чәчеләчәк. Орлыклар алынган, техника каралган. Хуҗалыкларга көнбагыш орлыгының – 36, кукурузның – 50, шикәр чөгендеренең 83 процентын читтән кайтарту планлаштырыла.

– Хәзерге вакытта орлыклар кайтару эше дәвам итә. Бу мәсьәләдә бер проблема да юк. Ашламаны, узган ел белән чагыштырганда, һәр гектарга 14 килограммга күбрәк әзерли алдык. Техника да әзер. Аларны һәр район буенча карап чыгачакбыз, – диде Наил Залаков.

Министр урынбасары әйтүенчә, уҗым культуралары барысы да яхшы хәлдә. 472 мең гектардагы игеннәрне тукландырырга кирәк булачак. Тик яңа уңыш җыеп алганчы, узган елгысын урнаштырасы бар бит әле. Ә хуҗалыкларда ул шактый күп – 1,3 млн тонна.

– Бу мәсьәлә бар, – дип ачыклап китте Наил Залаков. – Элеваторда шунның кадәре ашлык саклана. Аның бер өлеше орлыкка китәчәк. Июльгә, яңа уңыш алганчыга кадәр, терлекләргә дә ашатылыр, дип уйлыйбыз. Ләкин якынча 600 мең тоннасы элеваторда калырга мөмкин. Безнең һәрвакыт бер елдан икенче елга күчә торган иген бар иде. Ул уртача алганда 300 мең тонна була торган иде. Элеваторлар бер вакытта да бушап калмады. Быел, чыннан да, запас күбрәк булачак. 2010 елда, корылык булганда, без бөтенләй ашлыксыз калган идек. Анысы да яхшы түгел. Шуңа күрә саклауның альтернатив ысулларын кулланырга кирәк.

Проблемалар булса да, фермерлар чәчүлек мәйданнарын киметмәгән. Наил Залаков әйтүенчә, киресенчә, ашлама, орлык тагын да күбрәк кертелгән, техника да яхшырак әзерләнгән.

– Аңлашыла инде, без һәрвакыт табышны күбрәк алырга, хакны арттырырга телибез. Ләкин авыл хуҗалыгында «эшләргә кирәк» дигән нәрсә бар. Бер ел икенчесенә охшамый. Акрынлап барысы да үз урынына кайтачак. Бөртеклеләрне чәчәр өчен ярдәм алдык. Киләчәктә бәяләр тигезләнәчәк, – диде Наил Залаков.

Журналистлар министр урынбасарының уңыш буенча фаразлары белән дә кызыксынды. Тик, гадәттәгечә, ул бу сорауга җавап бирүдән баш тартты.

– Мин күрәзәче түгел, шулай да барлык ихтыяҗны капларлык ашлык үстерергә өметләнәбез, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Әйтеп кенә бактым

Эт белән әңгәмә

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Кибет ишеге төбендә бер эт ята. Язгы кояш нурларында мәлҗерәп, рәхәтләнеп йоклый ул. Кибеткә керүчеләргә бераз комачауласа да, типкәләп куып җибәрмиләр үзен, әйләнеп узалар. Урам этенең татлы йокысын бүләселәре килми. Хәер, урам эте микән ул? Йолкыш кыяфәтле түгел, йоннары да шоп-шома. Эткә бик әкрен генә: «Шарик, Тузик, Сарбай...» – дип дәшеп карыйм – йоны да селкенми. Димәк, исеме затлыдыр, кайчандыр хуҗасы булгандыр, картайгач: «Инде үз көнеңне үзең күр», – дип, урамга куып чыгарганнардыр. Әйтүләренчә, урам этләре уртача 9–12 ел яши, 20 елга хәтле тарта алганнары да бар икән. Кеше гомере белән чагыштырсаң, җиде яшьлек эт җитмештән узган кеше яшендә була. Димәк, без синең белән яшьти дә әле, кем, ни, исемеңне оныттым. Егет чагың булса, кеше аяк астында шулай ваемсыз гына йоклап ятмас идең. Үземнән беләм, соңгы вакытларда мине дә гел йокыга тарта. Ашап алгач бигрәк тә.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, машинамны кабыздым. Двигатель тавышына да сикереп тормады эт. Бер күзен генә ачып, үпкәләгәндәй миңа карап куйды. Төшенең иң кызык җирендә уятканым өчен бераз ачуы килде, ахрысы. Гаеп итмә, яшьти, ни дисәң дә, эт – кешенең дусты бит, шуңа күрә сиңа сүз кушасы килеп китте. Кайвакыт эт тормышы белән кеше тормышын чагыштырам да бик күп уртаклыклар табам. Безне хәтта бер үк чирләр интектерә икән, сездә дә кан басымы уйный, күзләрдә катаракта, гомуми психоз, тын кысылу, пес итә алмый азаплану, диабет була, хәтта рак, эпилепсия белән дә авырыйсыз икән. Син дә тормыш көзләренә кереп барасың икән, яшьти. Мин әле махы бирмәскә тырышам, иртә торам, соң ятам, көн саен эшкә йөрим. Ә син күбрәк яту ягын карыйсың, күз карашыңда – битарафлык. Минем күзләрдә дә шайтан уты уйнамый үзе, ну тормышка гамь бетмәгән әле. Яшь кызларны күрсәм, күңел дә җилкенгәләп куя. Ә сине яшь этләр бөтенләй кызыксындырмый бугай. Әнә кайберләре сиңа карап тора да, койрыгың да селкенмәвен күргәч, китеп баралар.

Әйе, тормышыбызда уртаклыклар күп безнең, яшьти. Бездә – бомжлар, сездә – урам этләре. Без караучысыз калсак, картлар йортына керәбез. Сезнең өчен приютлар эшли. Сез дә – дәүләт кайгыртуында. Хокукларыгыз бозылмасын өчен, әледән-әле законнар кабул ителә. Дәүсовет утырышларында хуҗасыз калган, ягъни урам этләре язмышы турында күбрәк тә сөйлиләр әле. Мин моны парламент хәбәрчесе буларак әйтәм. Эт белән кеше арасында аерма шул гына: без – уйлый, фикерли белә торган хайваннар. Сезнең белән исә инстинктлар гына идарә итә. Сез бәхетле, сезнең бернинди борчу-хәсрәтегез юк. Булыр иде, сез борчу-хәсрәтнең ни икәнен белмисез. Сез теләсә кайсы җәмгыятьтә матур гына яши аласыз, ә без – юк. Чөнки бәндә баласы кайчак үзенең юләр уйлары белән яшәешнең ямен җибәрә. Сезнең милләтегез дә юк. Шуңа күрә милләтара ызгышлар, шул нигездә килеп чыккан олы орышлар сезгә янамый. Милләтегез булмагач, телегез дә юк сезнең. Кызык, япон эте Казанга килсә, безнең этләр белән нинди телдә сөйләшер иде икән? Без, татарча белгәч, бөтен төрки дөнья белән аңлаша алабыз, ә япон этләре югалып калырга мөмкин. Мин әле, яшьти, Татарстан этләре, шул исәптән син дә, кәнишне, ике дәүләт телен дә белми микән әле дип шикләнәм. Мәсәлән, хәзер сиңа аяк тибеп: «Пошел вон!» – дисәм дә, «Кит әле моннан!» – дип кычкырсам да, шундук торып китәчәксең. Хәзергә кычкырмыйм, йокла. Сезгә – этләргә дә ана теле ана сөте белән керәдер инде, безгә дә шулай. Ә дәүләт телләре турындагы закон ана телебезгә мәхәббәтне тагын да ныгыта, аны җил-яңгырдан саклый. Ә сезнең тел – интернациональ тел инде ул. Немец эте дә, француз эте дә, японныкы да «вау да вау, хау да хау» дип өрә, бертөрле үк чиный, шыңшый. Һәм сезнең телне берәү дә кыса, бетерә алмый.

Әйткәннәрем эт тормышын мактавым түгел. Киресенчә, адәм баласы инстинктларга гына корылган тормышта яшәмәсен иде, диюем. Эт белән әңгәмә кору, үзенчә, күңел бушату гына инде. Укучы аны «Кызым, сиңа әйтәм, килենем, син тыңла» дип кабул итәр.

ТРАМПНЫ УТЫРТУ

Чәршәмбегә каршы төндә Америкадан Трампка бәйле хәбәрләр ишелеп килде. Трамп үзенең социаль челтәре Truth Socialда: «Түбән Манхэттенга юл тоттым. Бөтенләй сюрреалистик булып тоела: алар мине кулга алырга телиләр. Моның Америкада баруына ышанасы килми», – дип язып куйган, диделәр. Чынлап та, Америка тарихында элекке Президентның кулга алынуы – күрелмәгән хәл. Ләкин җинаять эшләгән икән, нигә дип кулга алмаска ди әле? Көньяк Кореяда, әйтик, 1980 елдан соң идарә иткән сигез Президентның дүртесен утырттылар, берсе үзенә кул салды.

Трамп үзен гаделлек тарафдары дип саный. Социаль челтәренең исемен татарчага тәрҗемә итсәк тә, «социаль гаделлек» дигән сүзтезмә килеп чыга. Тагын бер нәрсәне искәртик: Россиянең рәсми хакимиятләре 2016 елдан 2020 елга кадәр дөньяның иң зур державасы белән идарә иткән дуамал бу кешегә җылы, теләктәш мөнәсәбәттә. Ул үзе әле дә Путинны «шәп егет» дип атый. Хәер, Төньяк Корея лидеры да, Талибан* җитәкчеләре дә – Трамп квалификациясе буенча, «шәп егетләр». Үзен курку белмәс харизматик итеп танытуга карамастан, президентлык срогында бер тапкыр да Путин белән махсус визит ясап, зур сөйләшү уздыра алмады. Ике ил арасында бер килешү дә төзелмәде. Америкада аны «Кремль агенты», «Президентлыкка Путин булышлыгы белән килде» дип саныйлар иде. Лидерларның үзара делегацияләр җыеп очрашуы шул сәбәпле була алмады. Курыкты Трамп. Сүздә генә каһарман булып калды.

Ә бит Америка – Россия хезмәттәшлеге бик зур нәтиҗәләргә китерә ала иде. Шуңа күрә Трампның «Украина – Россия конфликтын бер тәүлек эчендә туктата алам», «Мин президент булсам, Путин Украинага керергә куркачак иде» дигән сүзләрен колак яныннан гына үткәрәбез, популизм дип саныйбыз.

Америка олигархы, хакимият дилбегәсен кулга алганда, MAGA – Make America Great Again дигән девизны байрак иткән иде. Безнеңчәгә әйләндерсәк, «Америкага үткәндәге бөеклеген кире кайтарыйк» килеп чыга. Бу язманың төп фикере, укучыга авторның әйтәсе килгән сүзе «үткәндәге бөеклек» дигән гыйбарәдә ята. Әйе, дөньяның иң куәтле державасы – дөнья океанына гаҗәп зур сандагы очкыч йөртүче кораблар төркеме чыгара ала торган, иң югары технологияле кораллар белән коралланган, глобаль икътисадны үз кубызына биеткән, үз сәясәтенә каршы килүчеләрне кискен җәзага тартырга яраткан дәүләт – бүген йогынтысын югалтып бара. Трамп сайлау алды платформасы итеп кулланган девиз американнарның үзләренең дә бөеклекнең үткәндә калуын танулары турында сөйли. Ә бит СССР таркалганнан соң, үзләрен дөнья кендеге, бердәнбер полюс итеп тоя башлаганнар иде. Тәкәбберлек файдага булмады: сәясәтчеләре вагайды, лидерлыкка күтәрү өчен эштие суынган картлардан башка шәхесләр таба алмадылар. Тышкы сәясәт стратегиясе гадәттән тыш начар, оттырышлы итеп эшләнде, уңга-сулга санкцияләр өләшү Вашингтонның үзен изоляция хәленә куя язды. Илнең эчке тормышында үзәктән качу процесслары кузгалды, гражданнар сугышы исе килә башлады. Мондый вазгыятьтә илнең потенциалын куллана белгән, белеме һәм эрудициясе ташып торган эшлекле яшь лидер мәйданга чыгарга тиеш бит инде. Карт бүреләр акрын гына үз урыннарына барып басарга, көчле юлбашчыга юл куярга тиеш. Байден – әлбәттә, сәясәттә зур тәҗрибәгә ия кеше. Моннан егерме-егерме биш еллар элек үз сүзен кискен итеп әйтә һәм тормышка ашыра да алган булыр иде. Хәзер юк, вакыты үтте, картайды абзый. Әмма вакыйгалар агышына карасак, 2024 елгы сайлау кампаниясендә һаман да шул ике көпшәкләнгән, комы коелган лидерлар бил тартышыр кебек.

Трампның Нью-Йорк судына чакырып китерелеп, пүчтәк кенә вакытка кулга алынуы – АКШта сайлау алды кампаниясенең башлануы гына ул. Аңа 34 пункттан торган гаепләү белдерделәр һәм шуның берсе генә – 2016 елгы сайлау алдыннан порноактриса Сторми Дэниэлска Трамп белән бозык мөнәсәбәтләре турында телен тешләтү өчен түләнгән 130 мең доллар акча документы турындагысы гына мәгълүмат кырына чыгарылды. Бер-ике көн элек Америка телевидениесе дә башка гаепләүләрнең нидән гыйбарәт икәнлеген белми иде. Игътибар итегез: элекке лидерны фахишә белән бозык мөнәсәбәтләре өчен түгел, шуңа бәйле рәвештә ялган

pixabay.com

документ куллануы өчен гаеплиләр. Барлык җинаятьләрен дә бергә кушып хөкем итсәләр, Трампка 136 еллык төрмә җәзасы тиеш булачак икән. Fox News телеканалы шулай дип хәбәр итә. Трампның элекке киңәшчесе Джон Болтон Лаврентий Бериянең: «Кешесе булса, статьясы табылыр», – дигән сүзләрен китерде, ягъни шеф «сөттән ак», аны гаепсезгә гаеплиләр. Трамп үзе дә шулай дип саный. Судның яңа утырышы 4 декабрьгә билгеләнде. Кайбер күзәтүчеләр, сайлау алды кампаниясе кызганда, Трамп суд мәшәкатьләреннән бушамасын өчен шулай эшләделәр, дигән фикер уздыра.

Америка картлары хакимлек өчен көрәшкәндә, державаның эчке тормышында да, тышкы геосәясәт мәйданында да токмачлар куера. JPMorgan – дөньяның иң эре банкларының берсе: «АКШтагы Silicon Valley Bankның җимерелүеннән башланган банк кризисы дәвам итә һәм аның нәтиҗәләре күп еллар буена үзен сиздерәчәк», – дигән белдерү ясады. Австралия разведкасы башлыгы Эндрю Ширер: «АКШның технологик өстенлеге зәгыйфьләнә, Һинд океаны – Тын океан көчләр балансы АКШтан һәм аның аркадашларыннан читкә күчә», – дип сөйләп ташлады. Каршы якның көчәюен тотып торып булмаячак, дип әйтәсе килә. Малайзиянең Премьер-министры долларга бәйлелекне дәвам иттерергә сәбәпләр юклыгын бер дә курыкмыйча әйтә. Ил Һиндстан белән милли валюталарда сәүдә итешү турында килешү төзеп өлгерде инде. Хәтта французлар Кытай белән юаньда сату-алу килешүе төзеделәр.

Кытай арадашлыгы белән стратегик дошманнар – Согуд Гарәбстаны һәм Иран – үзара мөнәсәбәтләрен яхшыртты һәм хезмәттәшлек башларга җыеналар. Кытай йогынтысы Якын Көнчыгышта АКШныкын узып китте. Гарәп – Кытай сәүдәсе рекордлы саннар күрсәтә һәм юаньга күчеп бетеп бара. Гарәпләр Байденның «кара алтын» чыгаруны арттыру турында үтенечен колакка да элмәделәр, нефть чыгаруны киметеп, үз мәнфәгатьләрен алга сөрүне яхшырак дип таптылар. Бүген Әр-Рияд акча яңгырында коена һәм аны кая куярга белми. «Әль-Хиләл» футбол клубы Мессины бер елга 400 миллион долларлык хезмәт хакы вәгъдә итеп үзенә чакырды.

Юк, һич тә Америка йогынтысы бетте, алар берни дә эшли алмыйлар дип әйтергә теләмим. Дәүләтләр буйсынып ук бетмәсәләр дә, АКШ санкцияләрен таныйлар әле. Һиндстанның дәүләт банкы Россия нефтенә 60 доллардан артык бәя куйган сәүдә килешүләрен үткәрүдән баш тартты. Моңарчы Һиндстанның нефть эшкәртү заводлары Россия нефте өчен Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дирһәмнәре белән түлиләр иде. Бу аларга санкцияләрнең бозылуын яшерү мөмкинлеге бирде. Әмма хәзер Bank of Baroda бу ысулны хәвефле дип тапты, икенчел санкцияләрдән куркып, Көнбатыш таләбенә буйсынырга булды.

АКШ гегемонлыгы йомшарды, ләкин барыбер дәвам итә. Дәүләтләр, милли валюталарда сәүдә иткәндә дә, эталон итеп долларны ала, валюталарның кыйммәте долларга карата курслары белән бәяләнә. Барлык илләрнең дә резервларында доллар төп урын алып тора. Хакимияткә Трамп килсә дә, Байден калса да, Америка мәнфәгатьләрен алга сөрәчәк. Ләкин америкалылар «Трампны утырту» циркын башлап җибәреп, сайлау алды көрәшендә креатив идеяләргә кытлык барлыгын күрсәтә. Иң мөһиме: мәйданга чыгарлык яңа лидерлар күренми. Озак сроклы перспективада бу хәлләр Американы «утыртырга» мөмкин.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

* Талибан – Россиядә тыелган оешма.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СЫЗЛАВЫК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Аптыраш

– Сыерны авыл халкы бераз файдасы булсын дип асрый инде, – ди Яшел Үзән районының Акъегет авылы халкы. – Бездә сөтне Ульяннан килеп җыялар. Кышын литрын 25 сумнан тапшырган идек, февральдә – 22, мартта 21 сумга төшерделәр. Кыскасы, сөт бәясе ай саен кими. Болай булса, сыерны бетерәбез, диючеләр дә күп. Бераүнең дә юкка көч түгәсе килми бит. Матбугатта авыл хуҗалыгын үстерергә, мал санын арттырырга кирәк, дип гел сөйлиләр. Алай булгач, ник бер чарасын күрмиләр икән?

Мондый эчтәлектәге хәбәрләр газетабызның социаль челтәрләрдәге теркемнәренә көн саен килеп тора, соңгы айда гына да редакциягә моң-зарын җиткерүчеләр саны бермә-бер артты.

– Ел башында сөткә 26 сумнан түләделәр. Башка районнарда 30–31 сум булса да, үзебезнең 26 сумга да риза идек. Тик февральдән бәяләр ярты ай саен төшә башлады. Инде 1 апрельдән 18 сум түләячәкләр, дигән хәбәр килеп иреште. Без аптырашта, – дип шалтыратты тагын бер укучыбыз – Апас районының Зур Болгаер авылыннан Алсу Хәсәенова.

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, әлеге вакытта республикада җитештерелгән сөтнең 85–90 проценты үзебездә эшкәртелә. Ләкин министр урынбасары Наил Залаков сүзләренчә, бу гына илне сөт продуктлары белән тулысынча тәэмин итми.

– Ике ел бездә сөт бәяләре тотрыклы булды, – диде ул, – яхшы түләнә иде. Әлеге вакытта да башка төбәкләр, илләр белән чагыштырганда, бездә бәяләр югары. Ләкин сөт продуктлары, коры сөт – биржа продуктлары. Бүген бөтен дөньяда коры сөткә биржа бәясе төште. Һәм болар барысы да базарга йогынты ясый, – диде ул. – Әлеге бәя төшүгә сезонлы кимү дип карарга кирәк. Әйе, бу безнең өчен начар, сөт җитештерүчеләр күп акча югалта, ләкин шул ук вакытта алар зыянга эшләми. Базар тотрыкланачак.

Мине алдан ук, сөт заводлары белән элемтәгә чыгарга да тырышма, бу темага сөйләшмәячәкләр, дип кисәтеп куйганнар иде. Берничәсенең телефон номерларын җыйсам да, җавап бирүче булмады. Исемен күрсәтмәү шарты белән генә Биектау районы сөт комбинаты вәкиләре безне кызыксындырган сорауларны бирдем. Аның әйтүенчә, сөт бәяләре төшүнең берничә сәбәбе бар. Аларның берсе – сөт продуктларының аз сатылуы, халыкның сатып алу дәрәҗәсе кимү, читтән коры сөт күп кертелү.

– Монда бер генә сәбәпне аерып алып карап булмый, – диде ул. – Бер сәбәп икенчесен китереп чыгара. Ни өчен бу шулкадәр кинәт булды – анысын үзебез дә аңламыйбыз. Аннан соң коронавирус аркасында Белоруссия Кытайга җибәрмәгәч, коры сөт Россиягә күпләп керә башлады. Дөньядагы вазгыять тә йогынты ясый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ул бәяләрнең алга таба тагын да төшәчәген әйтте.

– Бәяләрнең тагын күпмегә төшәсен әйтеп булмый, тик шунысы төгәл билгеле: аска тәгәрәү дәвам итәчәк. Җитештерүне киметеп булмый, шуңа күрә без продукцияне складка җыябыз. Әле ярый безнең продукцияне озак вакыт саклап була. Тик бу да проблеманы чишү юлы түгел. Без барыбыз да бер арбада, барыбызның да көймәсе комга терәлгән, – диде ул.

Сүз уңаеннан, NielsenIQ мәгълүматлары буенча, узган ел эремчекле десертлар сату – 18,6, йогыртлар – 15,2–17,3, каймак, эремчек, кефир 1,9–4,2 процентка кимегән. Күпләп сату компанияләре ассоциациясе президиумы рәисе Игорь Караваев әйтүенчә, эре сәүдә нокталарында йогыртлар һәм эремчекле десертлар сату 10 процентка азайган. Соңгы вакытта халык сөт, май, каймак, кефир һәм сырлар сатып алуга өстенлек бирә икән. «Коммерсантъ» газетасы хәбәр иткәнчә, халыкның сатып алуы кимегәнлектән, сөт продуктларын әзерләүче кайбер эре җитештерүчеләр сөт китереп торучылар белән килешүләрен өзә башлаган.

Хәер, язманы әзерләгәндә, үзебезгә дә шундыйрак эчтәлектәге фикерне ишетергә туры килде. Актаныш районының Киров авылыннан Мәрьям Сабитова сөт тапшыруның зур бер проблемага әйләнеп баруын әйтте.

– Үзебездә дә, күрше-тирә районнарда да сөтне кабул итми башладылар. Бик нык тикшерәләр, – диде ул. – Төрле сәбәпләр табып, кире борган очраклар да арта. Белоруссиядән бик күп коры сөт кергән, диләр. Шуңа күрә авыл апасы сөтенең кирәге калмаган. Бәяләр ел башыннан 4–5 сумга төште. Бүген районда 21–22 сум тирәсендә тора. Әле тагын төшә, дип сөйлиләр. 12 сумга гына калырга да мөмкин икән. Сөт заводы үзебезнең авылда гына. Алар да сөт җыючыларга шушы ук сүзне сөйли. «Бөтен Россия буенча вазгыять катлаулы, кабул итмибез», – дип әйткәннәр икән. Бу – авыл хуҗалыгын тулысынча юкка чыгару инде, – диде ул.

Контроль кирәк

«Ембулат» сәнәгать кооперативының икътисад һәм финанс буенча рәис урынбасары Алмаз Фәсхетдинов әйтүенчә, сөт эшкәртүчеләр барысы да диярлек бер сүзне кабатлый: мул уңыш җыеп алынды, күп сөт савылды, шулай ук алар продуктның сатылмавына һәм халыкның сатып алу дәрәҗәсе кимүгә дә басым ясый. Тик аларның сүзләренә генә ышанырга ярыймы? Менә анысы шик уята, дигән фикерен әйтте әңгәмәдәшебез.

– Монда антимонополь хезмәтеннән башка берничек тә булмый. Алар җитди тикшерү уздырырга, сөт базарын контрольгә алырга тиеш. Бәлки бу – эшкәртүчеләрнең үзара килешүе генәдер? Без бит аны тикшерә алмыйбыз. Сөт заводларына уртак тел табып, бер-берсе белән килешеп эшләргә кирәк. Сөткә ихтыяҗ һәрвакыт бар. Без һәрвакыт отышлырак юлларны сайларга тырышабыз. Кайсы завод күбрәк бирә, шуңа тапшырабыз. 2022 елдан безнең хуҗалыкта гына сөтнең үзкыйммәте 24–25 сум иде. Аннан да төшсә, малны бер көн тотудан да мәгънә юк. Ә шәхси хуҗалыкларда ул тагын да күбрәк. Иген сатып табыш алдык дип, хуҗалыклар, оешмалар кергән акчаны саклауга куймый. Ул аны техника, орлык сатып алуга, фермаларны карауга яки башка чыгымнарга тота, – диде ул.

Сыйфат бәя күтәрә

Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров фикеренчә, сөт җыю һәм эшкәртү буенча корпоративлар сөт бәяләрен югары дәрәҗәдә саклап калырга ярдәм итәргә тиеш. Хәзерге вакытта республикада шундый 24 кооператив эшли.

– Сөт хакы яхшы булсын өчен, республиканың һәр районы үз сөтен үзе эшкәртүне оештырырга тиеш. Без башка төбәкләргә әзер продукт алып чыгасы урынга, чимал ташыйбыз. Күпләргә шулай уңайлы, тик ул сөт безгә, бәясе өстәлеп, кабат әйләнеп кайта бит. Акча районнан, авылдан китә дигән сүз, – ди ул.

Дөрес, сөт башка төбәкләргә, шәһәрләргә дә, үзебезнең заводларга да китә.

– Сөт бәяләре һәр районда төрлечә. Аны, гадәттә, арадашчылар хәл итә. Безнең табынга килеп җиткәнче, сөт ким дигәндә өч кул аша уза. Һәм һәркем үз файдасын күрергә омтыла. Ә табышның иң азы сыер савучыга, терлек асраучыга эләгә. Монда дөрес сәяси алым һәм җитди контроль кирәк. ФАС бәяләрне һичшиксез күзәтеп торырга тиеш. Башкача булганда, авыл апасы бер вакытта да табыш ала алмаячак. Башта ул сыерыннан баш тартачак, аннан соң каз сатып алачак. Тора-бара бөтенләй сатып алуга гына күчәчәк. Әлеге вакытта республикадагы барлык терлекнең 30 проценты шәхси хуҗалыкларга туры килә.

Игътибарны кооперативларга бирергә кирәклегенә министр урынбасары Наил Залаков та басым ясады.

– Түбән бәя булмасын өчен, күбрәк сөт савып алырга түгел, ә аның сыйфатлы булуына омтылырга тиешбез. Шәхси хуҗалыкларда ул тагын да начаррак. Шуңа күрә соңгы ике елда без кооперативлар белән эшләүгә күчүне алга сөрәбез. Бүген республикада сөт тапшыручы хуҗалыкларның яртысы аны кооперативларга тапшыра. Әгәр шәхси хуҗалыклардан 600 мең тонна сөт савып тапшырыла икән, аның 400 меңе кооперативлар аша эшләнә. Бүген аларда бәя 24–25 сум тирәсендә тирбәлә. Бәя безнең кулда. Безгә бары тик дөрес, сыйфатлы, системалы итеп эшләргә генә кирәк.

Тик Алмаз Фәсхетдинов әйтүенчә, кооперативларның үзләренә дә җиңел түгел.

– Болай барса, башта – шәхси хуҗалыклар, аннан соң фермерлар терлекләрен бетерә башлар. Ахырдан эре комплекслар гына калыр. Хәзер икмәккә дә, сөткә дә бәя төшә. Бар халык терлеген суеп сата башласа, итенә дә бәя төшәчәк. Бу безгә кирәкме? Юктыр, дип уйлыйм. Шуңа күрә җитәкчелектән җитди адымнар көтәбез. Элек безгә пальма мае күп керде. Тыя алмадылар, чөнки сөт дефициты башланыр, дип куркалар иде. Менә хәзер аны кимету вакыты җитте. Чын сөткә ихтыяҗ артыр иде. Чит илгә чыга торган продуктларны да күбәйтергә мөмкин бит.

Белгеч фикере

Людмила МАНИЦКАЯ, Россиянең Сөт берлеге советы рәисе – директоры:

– Мөрәҗәгатьләр Россиянең барлык субъектларыннан килә, шул исәптән Татарстаннан, Тула, Вологда өлкәләреннән, Красноярск, Краснодар крайларыннан. Сөт эшкәртүчеләр бәя төшүне сөт продуктлары куллану кимүгә бәйләп аңлата. Монда әчке базарны карарга кирәк. Узган ел халыкның кереме, реаль хезмәт хаклары кимеде. Инфляция күрсәткечләре, ярлылык чигендә яшәүчеләр саны – болар барысы да йогынты ясый. Россиянең Сөт берлеге мондый вазгыятьтә дәүләт ярдәме артырга тиеш дип саный. Шул исәптән сатып алу бәяләре төшүне өлешчә каплар өчен, максатчан өстәмә субсидия бирүне карарга кирәк. Саклана торган артык коры сөтне алу ягын карасалар да нәтиҗәле булыр иде. Ләкин әлегә сөт базарында мондый инструмент юк. Моннан тыш, безнең фикеребезчә, сәүдә челтәрләре продукциягә бәяне 35 проценттан да арттырырга тиеш түгел, чөнки сөт продуктлары социаль әһәмияткә ия.

Сораштыру

СЕЗДӘ НИЧЕК?

Тәскирә МИНАҖЕВА (Аксубай):
– Без сөтне 23 сумга тапшырабыз.

Рушания ГЫЙМАДИЕВА (Алексеевск):
– Бездә сөт бәяләре ярты ай саен төшә. Бу – бүген безне борчыган иң авыр сорау.

Алия ӘГЪЗАМОВА (Арча):
– Бездә бер ай эчендә сөт хакын шундук 2 сумга төшерделәр. Халык арасында, 15 сумга кадәр төшә, дигән сүзләр дә йөри.

Раилә ХӘСӘНОВА (Балык Бистәсе):
– Бездә бер ай эчендә 3 сум 50 тиенгә төште.

Рөстәм ФӘТКУЛЛИН (Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылы):
– Халыктан җыелган сөткә гыйнварда 23 сум түләгәннәр иде. Февральдә 24 сумга күтәрелде дә мартта 19 сумга төшеп утырды. 1 апрельдән 18 сумнан түләячәкләр.

Хөрия ҖИҺАНШИНА (Буа районы Яңа Чәчкап авылы):
– Сөт хакы ун көн саен кими. Март башында – 23, уртасында 21 иде, ә ахырында 17 сумга калды.

Чулпан ҺАДИЕВА (Кукмара районы Бакчасарай авылы):
– Кышын сөтнең бер литрына 31 сумнан түләделәр. Бүген ул – 25 сум.

Гөлнур КАМАЕВА (Азнакай районы Урманай авылы):
– Безнең авылдан сөтне Мөслим егетләре килеп җыя. Февральдә 29 сумнан түләделәр. Сыерым яңа бозаулагач, мин мартта сөт сатмадым. Халыкка 27 сумнан түләгән, диделәр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ӨЗЕП БИРЕР КЕШЕҢ БУЛМАСЫН

istockphoto.com

Белмәсәгез белегез: Кызыл китапка кергән гөмбә һәм үсемлекләр җыйган өчен 9 елга кадәр төрмәгә утыртып куярга мөмкиннәр. Моңа өстәп, берничә миллион сумга кадәр штраф та яный. Россия Дәүләт Думасы депутатлары әнә шундый эчтәлектәге закон кабул итте. Гөмбәгә йөрергә яратучыларга нинди җинаять җаваплылыгы яный? Кызыл китапта ниләр бар? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Борчуга салган лилия

Авылдагы бакчабызда электән үк лилия чәчәгенең Кызыл китапта очрый торган «кедрә лилия» дигән төре үсә. Артык тәрбия дә таләп итми ул. Чия агачлары арасында елдан-ел суганнан үрчеп үсеп утыра. Гади лилиядән чәчкәләренең таҗлары көдрәләткән кебек бөтерелеп торуы һәм бер сабакта, кыңгыраудагы сыман, берничә чәчәк булуы белән аерыла. Бакчада чәчәкләр аннан башка да күп төрле. Шуңа күрә 1 сентябрь җиткәч, күрше-тирә балаларның укытучыга бирергә гөлләмә сорап керүләре дә – гадәти хәл. Ә чәчәк җыйганда төрлесе киселә иде. Иде дип әйтүем юкка түгел. Соңгы яңалыкларны ишеткәч, баласеннән башаяк дип, «Кызыл китапка кертелгән чәчәктән гомумән котылыргамы әллә?» дигән уй килде. Олылар булмаса, балалар өзмәс дип кем ышандырып әйтә ала?

6 апрельдә Россия Дәүләт Думасы РФ Кызыл китабына (Татарстанның үз Кызыл китабы да бар. – **Ред.**) кертелгән гөмбәләр һәм үсемлекләрне җыйган, тараткан һәм юкка чыгарган өчен җинаять җаваплылыгына тарту турында законны кабул итте.

Әле тикшерү барышында ук капма-каршы фикерләр яңгырый ул. Татарстан Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтыннан алынган мәгълүматларга караганда, Кызыл китапка кертелгән гөмбә һәм үсемлекләрне җыйган өчен тугыз елга кадәр төрмә һәм берничә миллион сумга кадәр штраф яный. Закон проектын тәкъдим итүчеләр фикеренчә, илдә сирәк очрый торган хайваннар, балыклар һәм кошларны юкка чыгаручыларга җинаять җаваплылыгы бар, ә үсемлекләр һәм гөмбәләр закон нигезендә сакланмаган. Әнә шул гаделсезлекне төзәтергә алынганнар да инде. Дөрес, табигатькә зыян салуын белә торып, моны махсус эшләүчеләрне генә җинаять җаваплылыгына тартачаклар, ди. Ягъни Кызыл китапка кертелгән үсемлек яки гөмбәне саксызлык аркасында өзүчеләргә борчыласы юк. Тик кулыңа кәрзин тулы гөмбә тоткан килеш каршыңа хокук саклаучылар килеп чыкса, алай түгел, болай ул, дип аңлатып кара син.

– Сафсата бит бу! – ди Биектауда яшәүче һәвәскәр гөмбәче Сәрия Зиннәтуллина. – Һәр гөмбәче саен бер сакчы куячакларммы әллә? Элек агулы гөмбә эләкмәсен дип шикләнсәк, хәзер Кызыл китаптагысы юлда ялгыш очрамасын инде. Аларны ничек белеп бетерәсең? Мәсәлән, ак усак гөмбәсе Кызыл китапка кертелгәнне беләм. Ул безнең як урманнарда да үсә. Аны берничәне кисеп җыйганым бар. Шундый ике-өч гөмбә өчен дә җавап бирәсе булачакмы? Гөмбә җыю бик ансат кына түгел шул. Арада бер-берсенә бик нык охшаган ялган гөмбәләр дә очрый. Мин таныш булган гөмбәләрне генә җыярга тырышам. Яз җиткәч, кәҗә гөмбәсенә (сморчки) чыгабыз. Җәй башында майлы гөмбәләр пәйда була. Җиләк пешкән чорда җирән гөмбә (рыжик) җыярга йөрибез. Көз патшасы – гөреҗдә (грузди). Ә иң тәмле гөмбәләрнең берсе – нарат гөмбәсе (боровик). Аны «патшалар гөмбәсе» дип тә атыйлар әле. Ул сирәк очрый, шуңа күрәме элек байлар нәкъ менә нарат гөмбәсен яратып ашаган, ди.

Биолог-бакчачы Дамир Гафуров әйтүенчә, гөмбәне кисеп җыю аның төр буларак юкка чыгуына беренче куркыныч тудырмый. «Гөмбә сабагыннан да, эшләпәсеннән дә үрчеми, аның тармакланган нечкә җепләр – гифлардан торган гөмбәлеге җир астында була», – ди ул.

631 төрле байлык

Белгечләр исә ашыкмаска киңәш итә. Бу юнәлештә эш алып баруның әһәмиятен дә искәртәләр.

– Республикадагы биологик төрлелекне саклап калу – мөһим мәсьәләләрнең берсе, – диде Татарстан Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Федор Батков моннан бер ай чамасы элек узган еллык коллегия утырышында. – Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда юкка чыгу куркынычы янаган җәнлекләр, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең 631 төре сак астына алынган.

Былтыр галимнәр, биологик төрлелекне ачыклау өчен, республиканың Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш һәм Яшел Үзән районнарында фәнни-тикшеренү эшләре дә үткәргән. Нәтиҗәдә бездә моңарчы очрамаган яңа сирәк төрләргә дә тап булганнар. Аларны ачыклау белән берләттән, саклау да мөһим, диләр комитетта.

– Бүген Кызыл китапка кертелгән аерым төр җәнлекләр һәм кошларны юкка чыгарган өчен закон нигезендә җинаять җаваплылыгы каралган, алга таба гөмбәләр һәм үсемлекләрне дә шул таләпләргә тәңгәлләштерергә телиләр, – ди дәүләт комитетының Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе мөдире Ринат Чиспияков. – Закон үз көченә кергәнче, шактый вакыт узачак. Чөнки тиешле документларны әзерләү зарур. Бу очракта, җәнлекләр һәм кошларга бәйле законнардагы кебек үк, юкка чыгарга мөмкин булган гөмбәләр һәм үсемлекләрнең аерым исемлеге төзеләчәк. Ягъни җинаять җаваплылыгы Кызыл китаптагы бөтен гөмбәләргә һәм үсемлекләргә дә кагылачак дигән сүз түгел. Арада аеруча да саклауны таләп итә торганнары бар. Аның үтәлешен кем һәм ничек тикшерәчәге дә билгесез. Бәлки, бу эшне Росприроднадзорга йөкләрләр, ә бәлки, төбәкләргә калыр. Бүген хайваннарны саклау өлкәсендә төгәл законнар эшли, тик үсемлекләргә бәйле тәгаен закон юк. Тәртип бозучыларга административ җаваплылык кына каралган.

«ВТ» юристы Булат Закиров сүзләренә караганда, Кызыл китапны өйрәнеп утыру теләге булмаса, танып белгән үсемлекләр һәм гөмбәләрне генә җыю хәерле.

– Йорт тирәсендә сирәк очрый торган чәчәкләрне үстерүчеләргә килгәндә, Кызыл китапка кыргый хайваннар һәм үсемлекләр генә кертелә. Ә «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» федераль канун нигезендә, аларны хуҗалыкта куллану катгый тыела. Ягъни үсентене Кызыл китапныкы булып саналмаган күрше төбәктән алып кайтсагыз да, бакчада сирәк очрый торган чәчәк утырту, аны үрчетү тыела. Әгәр ниндидер җилләр белән йорт тирәсенә Кызыл китаптагы чәчәк килеп эләккән икән, аңа кагылмавың хәерлерәк.

«Ун елга бер яңартыла»

Кызыл китапта ниләр бар? Бу сорау белән без КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтының Биоэкология, гигиена һәм иҗтимагый сәламәтлек кафедрасы мөдире, профессор Илгизәр **РӘХИМОВ**ка мөрәҗәгать иттек.

– Илгизәр Ильясович, Татарстанда ни өчен берьюлы ике Кызыл китап гамәлдә?

– Билгеле булганча, Кызыл китапта сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган җәнлекләр, кош-кортлар, гөмбәләр һәм үсемлекләр турында мәгълүмат теркәлгән. Татарстан Кызыл китабында Россиянекенә кертелгән бөтен хайваннар, кошлар, гөмбәләр һәм үсемлекләр бар. Безнең илебез бик зур. Күп кенә җирлекләрнең үзләренә генә хас булган флорасы һәм фаунасы бар. Аларның бөтенесен бер китапка туплап бетереп булмый. Шуңа күрә төбәкләр, илкүләм исемлекне тагын да киңәйтеп, үзләренең Кызыл китапларын бастыра. Без республикада сирәк очрый торган төрләрне махсус комиссия утырышларында карап тикшерәбез. Теге яки бу кошны, үсемлекне ТР Кызыл китабына кертү мәсьәләсе Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә хәл ителә. Шул рәвешле, ТР Кызыл китабы безнең җирлектәге җәнлекләрне, кош-кортларны, гөмбәләрне һәм үсемлекләрне тагын да яхшырак сакларга ярдәм итә.

– Кызыл китап еш яңартыламы?

– Закон нигезендә ун елга бер тапкыр яңартылып, яңадан басылырга тиеш. ТР Кызыл китабының өч басмасы чыкты инде. Мондый өлкәләр ил күләмендә дә күп түгел. Бу хакта горурланып әйтә алабыз. 2025 елда аның чираттагысын чыгарырга әзерлек эшләре алып барыла. Моның өчен ун ел буе мәгълүмат җыябыз. Теге яки бу сирәк очрый торган кош-корт яки җәнлеккә бәйле үзгәрешләрне, саны артуын-кимүен тикшерәбез. Махсус комиссия эшендә төрле тармак белгечләре, шул исәптән югары уку йортлары галимнәре дә катнаша. Мәсәлән, беренче басылган Кызыл китапта соры көртлек (серая куропатка) бар иде. Үз заманында аларның саны нык кимеде. Хәзер исә артты. Шуңа күрә соры көртлекне исемлектән чыгардык. Бүген Кызыл китаптагы берничә төр балык (араларында чөгә балыгы (стерлядь) да бар) һәм кайбер үсемлекләр турында бәхәс алып барабыз. Татарстанда җәнлекләр, кош-кортлар, гөмбәләр һәм үсемлекләрнең яңа төрләре дә очрап тора. Декабрь азагында узган утырышта гына сирәк очрый торган берничә төрле гөмбәне исемлеккә кертү турында фикер алыштык.

– Ә гөмбәчеләргә нишләргә? Урманга барган саен Кызыл китап күтәреп йөреп булмый бит.

– Бу хакта күптән сүз алып барабыз. Киләчәктә аерым бер сайт булдырырга телибез. Кешеләр аны кесә телефоны аша да ачып карый алачак. Тик моның икенче ягы бар: урманда интернет тотмаска да мөмкин. Шуңа күрә бу мәсьәләдә заманча технологияләр кулланыу уйлап бетерергә кирәк. Татарстанда әйләнә-тирә табигатьне саклау өлкәсендә зур эш башкарыла. Республикада вазгыять тыныч. Ә табигатьне саклау – һәркемнең эше. Шул ук кошлар да, җәнлекләр дә безгә кадәр үк булган. Без, кешеләр исә, бөтен нәрсәне үз кулыбызга алдык та, үзебезне җиһанда хуҗа итеп хис итәбез. Алар хуҗа, без түгел. Нинди генә эш башласак та, бирегә ничәмә-ничә еллар буе яшәгән җәнлекләргә, үсемлекләргә зыян салу куркынычы турында онытмасак иде.



14 апрельдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә ГЫЙЛАҖИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Акчамны кайтарып булмасмы?

Миңа – 76 яшь. Күптән түгел тешләремне караттым. Куйдырдым да. Барысына 45 мең сум акчам китте. Пенсиям 15 мең генә. Теш өчен түләгән акчаның бер өлешен кайтарып алып булмыймы?

ГЫЙЛЬМЕТДИН абыегыз. Казан, Отары бистәсе

Казанның 6 нчы салым инспекциясе өлкән белгече Рәмзия Мөхетдинова:
– Гыйльметдин абыйга теш куйдырган өчен берәр баласы акча түләгән очракта, аның 13 процентын кире кайтарып була. Бу очракта акча түләгән баласы килешү һәм чеклар белән салым инспекциясенә мөрәҗәгать итә ала. Әгәр пенсионер үзе түләгән булса, алар салым акчасын кайтара алмый.

Туганымны фатирдан ничек чыгарыйм?

Фатир алганда, бертуган апамның кызына да өлеш чыгарган идем. Янәсе, картаймыш көнемдә тәрбияләр. Тик ул балага мин кирәк булмадым. 5 елдан артык хәлемне дә белгәне юк. Фатирлы булыр өчен, үлгәнемне көтә микән? Әмма минем тырышып алган куышымны аңа калдырасым килми. Үземне караган социаль хезмәткәргә яздырмакчы идем. Ничек итеп шул кызның өлешен кире үземә аласы?

Кәтифә ХАЛИКОВА. Чаллы

«Ватаным Татарстан» газетасы юристы Булат Закиров:
– Бу туганыгыз пропискада булса, аны МФЦ аша гына төшереп булмаячак. Моны суд аша гына хәл итеп була. Бу кыз фатирдагы үз өлешенә өметләнә ала. Хуҗа фатирны кемгәдер васыять итәргә уйласа да, ул кешегә үз өлешен генә яздыра ала. Үлеп киткән очракта, социаль хезмәткәр – үз өлешен, туганы үз өлешен алачак. Әмма нидер язганчы яки эшләгәнче, иң элек ЕГРЛдан фатир турында белешмә алырга кирәк. Хәзерге көндә фатирга кемнәр хуҗа, арест салынмаганмы, алыш-биреш итү тыелмаганмы? Барысын да тикшертеп алу комачау итмәс.

Миңа өстәмә тиешме?

30 ел авыл хуҗалыгында хезмәт куйдым. Колхозда пешекче идем. Соңгы елларда авыл җирендә эшләүчеләр пенсиясенә өстәмә акча ала башлады. Миңа бирмиләр. Янәсе, тиеш түгел. Бу – дөрес хәлме?

Мәдинә АРСЛАНОВА. Лаеш районы

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Иминият пенсиясенә 25 процентка арттырылган билгеләнгән күләмдәге түләүне авыл хуҗалыгында 30 елдан да ким булмаган эш стажына ия һәм авыл җирлегендә яшәүче эшләми торган пенсионерлар алырга хокуклы. 2022 елдан башлап, пенсионерга билгеләнгән югары түләү ул шәһәргә күченгән очракта да саклана.

Иминият пенсиясенә билгеләнгән күләмдәге түләүнең арттырылган суммасын билгеләү хокукы бирә торган вазыйфалар һәм белгечлекләр исемлегенә 500дән артык һөнәр керә. Бу исемлек Россия Федерациясенең 2018 елның 29 ноябрендәге № 1440 Хөкүмәт карарында беркетелгән. Кызганыч, бу исемлеккә пешекче һөнәре керми. Шул ук вакытта Россия Федерациясе (РСФСР) территориясендә 1992 елның 1 гыйнварына кадәр колхозларда, машина-трактор станцияләрендә, колхозара предприятиеләрдә, совхозларда, крестьян хуҗалыкларында, авыл хуҗалыгы артельләрендә башкарылган эш, һөнәр атамасына, белгечлегенә яки вазыйфасына карамастан, «авыл» стажына кертелә.

Сугыш чоры балаларына нәрсә бирәләр?

Сугыш чоры балаларына Җиңү көненә ниндидер медаль бирәләр икән, дигән сүзләр йөри. Бүләкне бу категориягә керүчеләрнең барысына да бирәләрме, әллә аерым кешеләргә генәме икән? Медаль нинди дә булса ташламаларга хокук бирәме? Тагын 5 мең сум акча да бирәләр икән, дигән сүз ишетелде. Дөрес хәбәрме бу?

Фирая ЗАКИРОВА. Балык Бистәсе

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе **Рафаэль Гыйниятуллин** җавапны кыска тотты. Законда «сугыш чоры балалары» дигән категория юк, диде ул. Димәк, бәйрәм алдыннан сугыш чоры балаларын сөендерергә булмаячак.
Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков:
– Әлегә сугыш чоры балаларына берни дә каралмаган. Аларның күбесе – тыл ветераннарыдыр. Андыйлар өчен яңалык бар: быел аларга Җиңү көнендә бүләк таратачаклар.

«Ана даны» медале кемгә бирелә?

Биш бала үстерәбез. Якын-тирәдәгеләр «Ана даны» медале алып бетерде инде. Авыл башлыгыннан сорый башласак, сезгә тиеш түгел, ди. Кемнәргә бирелә соң ул?

ХӘНИФ. Арча районы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Рафаэль Гыйниятуллин:
– «Ана даны» медале биш һәм аннан күбрәк балалары булган, аларны тәрбияләүгә җаваплы һәм намус белән караган, сәламәт тормыш рәвеше алып барган, балаларының сәламәтлеген, белем алуын, физик һәм әхлакый яктан үсешен тәэмин иткән, аларны шәхес буларак үстергән әниләргә бирелә. Медаль бирелгән вакытта балигъ булмаган балалар саны бердән дә ким булмаска тиеш. Иң кечесенә 3 яшь тулуы мөһим. Болардан кала, медаль алуның тагын бер шарты – Россия гражданы булып, Татарстан территориясендә биш елдан озаграк яшәү. «Ана даны» медаленә бирү турындагы гаризаны оешма коллективы, җәмәгать берләшмәләре, социаль яклау бүлекләре тапшыра. Ул исә Татарстан Президенты Указы нигезендә карала.

Әлеге дәрәҗәле исемгә лаек булган хатын-кызлар, медаль белән бергә бер тапкыр акча хокукына да ия. Татарстан кануны (74-ТРЗ) нигезендә «Ана даны» медале иясе булган хатын-кызга биш бала тәрбияләп үстергән очракта 50 мең сум түләнә, алты һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләп үстергән очракта акчалата бүләк алтынчы һәм аннан соңгы һәрбер балага 10 мең сумга арта.

Үлгәнче санаторий күрерменме?

Бик күп төрле катлаулы операцияләр кичердем. Сәламәт җирем юк. Үземә тиешле юлламаны сорап, районгады Социаль фонд бүлегенә барган идем. Андагы кызлар минем белән тупас сөйләште. Пенсиям җитәрлек икән, сатып ал, дип чыгарып җибәрделәр. Мин бит кеше өлешенә кермим. Үземнең авыруларым буенча тиешле юлламаны гына эзләп йөри идем. Үлгәнче санаторий күрерменме?

Нәсимә МӨХӘММӘТҖАНОВА. Казан, Совет районы

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге матбугат үзәге җитәкчесе Альбина Никандрова:
– Без Нәсимә Мөхәммәтҗановага үзебезнең юнәлештән тиешле ярдәм чараларын яңадан кайтып йөрмим. Быел март аенда чүп ташлаган өчен 7555 сум акча түләргә дип квитанция килгән. Мин анда тормагач, чүп тә ташламыйм бит. Мин ул айларда монда, Казанда чүп ташлыйм. Ни өчен ике тапкыр түләтәләр? Күпме алдап була инде халыкны? Мин бу акчаны түләргә тиешме?

Әклимә МОРТАЗИНА. Казан

«ЖКХ» идарәче компания төбәк операторының матбугат үзәге:
– Кулланучы биш көн яки аннан күбрәк өйдә булмаган очракта, чүп өчен килгән акчаны яңадан исәпләтә ала. Моның өчен безнең сайтка кереп, «Документлар» дигән бүлектән үзегезгә тиешле гаризаны алып тутырып, безгә юллавыгыз кирәк. Шул очракта бер урында гына түли башлаячаксыз.

Ял эләгерме?

Бюджет өлкәсендә эшләүчеләр санаторийларга ике атнага бушлай бара ала, дип ишеткән идем. Дөрес сүзме бу?

НӘЗИЛӘ

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 16 апрелендәге 184 номерлы карары нигезендә, ташламалы шартларда санаторийга юлламалар белән Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары хезмәткәрләре тәэмин ителергә мөмкин. Ләкин моның өчен айлык уртача хезмәт хакының җан башына яшәү минимумының 500 процентыннан артмавы, белешмә белән расланган медицина күрсәтмәләре булу кирәк. Юллама алу өчен хезмәткәр эш урынындагы профсоюз оешмасына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Әгәр андый оешма булмаса, хезмәткәрнең яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органына барырга кирәк.

Зиратка юл бетәрме?

Авыл зиратына бара торган җирне бер кеше сатып алган иде. Ул үлеп китте. Инде хәзер бу урынны башка кеше сатып алган икән. Авыл кешесенең коты очып тора, шәхси кулларда булгач, зиратка ничек барырбыз соң? Әгәр ул кеше юлны ябып куйса...

ГАЛИЯ. Лаеш районы Пәрәу авылы

Лаеш районы башлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Айгөл Әмирова:
– Авыл халкы юкка борчыла. Зиратка илтүче юл район башлыгы контролендә алындыы. Җирнең хуҗасы аны ябарга тиеш түгел. Япкан очракта да, зиратка юлны башка урыннан ачып була. Әмма без, нинди хуҗа килсә дә, изге урынга юлны япмас, дип өметләнәбез.

Нигә дәүләт булышмый?

Балам белән Казанның Айдаров урамында урнашкан хастаханәгә эләктек. Мондагы хәлләрне күреп шаккаттым. Тумбочкалар юк, караватлар җитми. XXI гасырда шундый мескен хәлдәге хастаханәләр бар икән! Сүз бала сәламәтлеге турында бара бит. Дәүләт нигә булышмый икән?

РЕЗЕДА

Казан шәһәре Сәламәтлек саклау идарәсенең матбугат үзәге:
– Сез җибәргән хәбәрне ачыкладык. Әлеге медицина учреждениесе Казанда берәү генә. Бары тик биредә генә аллергияле балаларны агачлар яфрак яру һәм чәчәк ату сезонына әзерлиләр. 70 урынга исәпләнгән бүлектә бүген 110 кеше дәвалана. Урын җитмәү сәбәпле, башка бүлекләрдән диван һәм кушеткалар алып торганнар. Андагы табиблар хәлне вакытлыча күренеш дип аңлата. Алар әйтүенчә, башта әти-әниләр, ничек тә тизрәк шерену үтәр өчен, кушеткада ятарга да риза булып киләләр, ә аннары тавыш куптаралар. Бөтен кешенең дә сәламәт буласы килә. Табиблар аларны аңлаган кебек, алар да аңласын иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Фикер

Быелгы Тукай премиясен Флера Гыйззәтуллинага бирсеннәр иде. Ул моңа бик лаеклы. Кешене үзе исән чакта хөрмәт итәргә кирәк.

Венера ФАТЫЙХОВА. Арча районы Түбән Пошалым авылы

***

Озак еллар дәүләт оешмаларында эшләгән пенсионерлар эш урыннарын ташлап китәргә ашыкмый. Хезмәт хакын югалтмас өчен, алар җитәкчеләрнең киңәшчеләре, урынбасарлары булып йөриләр. Ул пенсионерлар заман таләбенә туры килерлек эшли аламы икән? Ялны тикмәгә генә бирмиләрдер инде. Яшьләргә урын бирсәгез иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА

10 апрель | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». Телесериал12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество»16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
00.00 «Каравай». Кузнечная мастерская 6+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Ком сәгате» 16+
01.45 «Рыцари вечности» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе» 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Ватандашлар». Рауза Хәйретдинова. Үткәннәрдән хатлар (субтитрлы) 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Калеб» 6+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». Многосерийный фильм (S) 12+
23.40 Премьера. Любовь Аксенова. «ПОЧКА» (S) 18+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Аросьева, Александр Константинов, Иван Шибанов, Фёдор Шувалов, Олег Алмазов. «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.50 Новости
07.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25, 23.55 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.25 Смешанные единоборства. URAL FC. Вячеслав Дацик против Джеронимо Дос Сантоса. Трансляция из Самары 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Иркутск» 12+
15.30 «Громко». Прямой эфир
16.55 Футбол. Товарищеский матч. Женщины. Белоруссия – Россия. Прямая трансляция из Белоруссии
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Запад». СКА (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
22.55 «Вы это видели» 12+
00.55 Баскетбол. PARI Чемпионат России – Премьер-лига. Женщины. 1/2 финала. МБА (Москва) – «Динамо» (Курск) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Магия большого спорта» 12+
03.30 Волейбол на снегу. Кубок России. Финал. Женщины. Трансляция из Нового Уренгоя 0+
04.35 «Наши иностранцы» 12+
05.00 «Светлана Ромашина. На волне мечты». Документальный фильм 12+

НТВ

04.50 Александр Половцев, Анна Котова-Дерябина в детективе «ФЕМИДА ВИДИТ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.10 «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
00.00, 00.40 Остросюжетный детектив «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
03.55 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.10 «Порча». «Ступени» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.20 «СУРРОГАТНАЯ МАТЬ» 16+
19.00 «ПОКА ВСЕ ДОМА» 16+
22.15 «Забота о важном» 16+
22.20 «ПОКА ВСЕ ДОМА» 16+
23.15 «КАТЯ И БЛЭК». 1-я – 4-я серии 16+
03.00 «Порча» 16+
03.25 «Знахарка» 16+
03.50 «Верну любимого» 16+
04.20 «Голоса ушедших душ» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
04.50 «Понять. Простить» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ДРУЖБА ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «ЩИТ И МЕЧ». «БЕЗ ПРАВА БЫТЬ СОБОЙ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.50, 15.05 «СТРАЖИ ОТЧИЗНЫ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Оружие Победы. Щит и меч Красной армии. У стен Сталинграда». Документальный фильм 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Самый загадочный узник Российской империи» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «Гагарин. Жизнь в хронике ТАСС». Документальный фильм 16+
00.25 «Собаки в космосе». Документальный фильм 12+
01.20 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
02.45 «Второй. Герман Титов». Документальный фильм 12+
03.45 «СТРАЖИ ОТЧИЗНЫ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

11 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». Телесериал 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан»16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Соотечественники». А. Арсланов. Мастер художественного слова 16+
00.50 «Каравай». Секреты казанского чаепития 6+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Музыкаль мәйдан» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар». Рауза Хәйретдинова. Үткәннәрдән хатлар (субтитрлы) 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе» 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «ПОЧКА». Многосерийный фильм (S) 18+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Первые лица» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Аросьева, Александр Константинов, Иван Шибанов, Фёдор Шувалов, Олег Алмазов. «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «География спорта. Иркутск» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 19.00 Новости
07.05, 15.00, 19.05, 21.20, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Шон Стрикланд против Насрудина Имавова. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 «Ты в бане!» 12+
15.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Восток». «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.35 Профессиональный бокс. Нокауты 16+
21.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Манчестер Сити» (Англия) – «Бавария» (Германия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Бенфика» (Португалия) – «Интер» (Италия) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Магия большого спорта» 12+
03.30 Волейбол на снегу. Кубок России. Финал. Мужчины. Трансляция из Нового Уренгоя 0+
04.35 «Голевая неделя РФ» 0+
05.00 «Якушин. Первый среди первых». Документальный фильм 12+

НТВ

04.50 Детектив «ФЕМИДА ВИДИТ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный детектив «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
03.55 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
10.35 «Забота о важном» 16+
10.40 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.35 «Порча». «Студия красоты» 16+
13.05 «Знахарка» 16+
13.40 «Верну любимого» 16+
14.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «КРАСОТА НЕБЕСНАЯ» 16+
19.00 «РОДНЫЕ И БЛИЗКИЕ» 16+
22.15 «Забота о важном» 16+
22.20 РОДНЫЕ И БЛИЗКИЕ 16+
23.05 «КАТЯ И БЛЭК». 5-я – 8-я серии 16+
02.55 «Порча» 16+
03.20 «Знахарка» 16+
03.45 «Верну любимого» 16+
04.15 «Голоса ушедших душ» 16+
04.40 «6 кадров» 16+
04.55 «Понять. Простить» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СТРАЖИ ОТЧИЗНЫ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «ЩИТ И МЕЧ». Телесериал. «ПРИКАЗАНО ВЫЖИТЬ...» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.50, 15.05 «СТРАЖИ ОТЧИЗНЫ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Комиссар госбезопасности». Документальный фильм. 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «УКРОЩЕНИЕ ОГНЯ» 12+
02.15 «НОЧНОЙ МОТОЦИКЛИСТ» 12+
03.25 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
03.50 «СТРАЖИ ОТЧИЗНЫ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 171 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе директоры **Галиәкбәрова** Рания Нәкыйп кызы; законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү район суды рәисе **Галишников** Константин Игорьевич, Татарстан Республикасы Буа шәһәр прокуроры урынбасары **Хазова** Татьяна Николаевна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада хокук тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары – хуҗалык идарәсе башлыгы **Губин** Александр Владимирович; республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен шәхси эшкуар **Давыдова** Фәридә Юныс кызы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татагролизинг» акционер җәмгыяте генераль директоры **Җиһаншин** Азат Илдус улы; актив иҗтимагый эшчәнлеге, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Камәретдинова** Рузалия Кыям кызы; оборона сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директорының ДОЗ буенча урынбасары – җәмгыятьнең баш инженеры **Мирханов** Наил Гакыйф улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Казан шәһәренең «Үзәк» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе генераль директоры урынбасары – «Волейбол буенча «Юность» олимпия резервы спорт мәктәбе» структур бүлекчәсе директоры **Морзаков** Рафикъ Хәсән улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары ярдәмчесе **Сәлахова** Алсинә Вазыйгулла кызы; хезмәтендә югары күрсәткечләргә ирешүе, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы буенча бүлеге тикшерү бүлекчәсе башлыгы, юстиция подполковнигы **Хәбибрахманов** Азат Марс улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары **Аюкасов** Рөстәм Анатольевич, Татарстан Республикасы финанс министры ярдәмчесе **Газизов** Айдар Сәлимҗан улы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы **Газизов** Ринат Марат улы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының идарә аппаратын финанслау бүлеге башлыгы **Гыймадиев** Динар Ислам улы, хезмәт ветераны **Мусин** Хәйдәр Исмәгыйль улы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының административ-хуҗалык бүлеге башлыгы **Хәйруллин** Илнар Нурислам улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы баш тикшерү идарәсенең Кама аръягы зонасы буенча хәрәкәт иминлегенә һәм транспортны эксплуатацияләүгә каршы җинаятьләрне тикшерү бүлеге башлыгы, юстиция полковнигы **Аксаков** Руслан Николаевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе бүлеге (шәхси состав белән эшләү бүлеге) башлыгы, полиция полковнигы **Баһавиев** Ленар Ринат улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Апас районы буенча бүлеге тикшерү төркеме башлыгы (тикшерү төркеме), юстиция подполковнигы **Идрисов** Марат Рәшит улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге тикшерү бүлеге башлыгы, юстиция подполковнигы **Исмәгыйлев** Руслан Рәис улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Отакулов** Олим Облакул улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының баш тикшерү идарәсе оешкан җинаятьчел эшчәнлекне тикшерү часте (идарә хокукында) башлыгы урынбасары, юстиция полковнигы **Сафин** Альберт Тәлгать улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең концерт бүлеге вокалчы артисты (солисты) **Әхмәдишин** Әмир Фәис улына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Филармония джаз-оркестры артисты **Оськин** Михаил Евгеньевичка, музыкаль башкаручы **Яруллин** Радик Вәлит улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧАМАСЫН БЕЛЕП КАБАСЫ

Кеше елына уртача 8 килограмм тоз ашый. Белгечләр моны бик зур сан дип атый. Көндәлек рационыбызның алыштыргысыз өлешенә әверелгән тозны чамалап кулланырга киңәш итә алар. Файдасы шактый булса да, чама хисе югалса, гади генә тоз да организмыбыз өчен дошманга әверелергә мөмкин.

Аш тозының без белгән һәм белмәгән яклары турында табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА сөйләде.

:: Тозның файдасы нәрсәдә?

– Организмыбыз тозсыз яши алмый. Ул, иң беренче чиратта, матдәләр алмашы өчен кирәк. Халык телендә «тоз» дип йөртелгән натрий хлориды мускуллар, гормоннар эшчәнлегендә дә катнаша. Безнең тән тукымасы, мускул, күзәнәкләр – барысы да суга мохтаҗ. Тоз исә аларга кирәкле суны организмнан чыгармыйча саклап тота.

:: Тозны чамадан тыш күп куллану куркынычмы?

– Бу, иң беренче чиратта, кан басымын күтәрә. Тозны чамадан тыш күп кулланган кешегә бөер һәм бавыр авырулары, атеросклероз килеп чыгу куркынычы да яный. Тоз күпкә китсә, организмдагы кальций юыла. Димәк, тешләр, сөякләр дә зәгыйфьләнә дигән сүз. Кальцийга кытлык аркасында остеопороз да барлыкка килергә мөмкин. Әйткәнемчә, тозның чамадан тыш күп керүе аркасында, организмда су тоткарлана башлый. Төгәлрәк әйтсәк, 1 г тоз 200 мл суны тоткарлый. Нәтиҗәдә кеше шешенергә мөмкин. Эчке әгъзалар эшчәнлегенә дә тискәре йогынты ясый бу. Тозны чамадан тыш куллану йөрәк-кан тамырлары авырулары, шикәр диабеты, яман шеш, хроник үпкә авыруы кебек чирләр килеп чыгу ихтималын да арттыра.

Белеп тор!

✓ Кеше көненә күп дигәндә 5 грамм тоз ашарга тиеш. Әмма чынбарлыкта саннар күпкә зуррак. Әйтик, Россиядә яшәүчеләр көненә уртача 12 г тоз ашый. Европа белән АКШта бу күрсәткеч 10 г тәшкил итә.
✓ Югары кан басымыннан интеккән кеше ашаган тозның көнлек нормасы 1 граммнан да артмаска тиеш.
✓ Күп кенә авырулар вакытында кешегә тозсыз диетада утырырга яки көн дәвамында ашаган тоз күләмен чикләргә туры килә. Аерым алганда, бөер авырулары, энурез, артык авырлык, шешенү, гипертониядән интеккән кешеләр көндәлек рационына шундый үзгәрешләр кертергә тиеш.

vk.com

:: Ни өчен, тозлы ризык ашагач, гел тозлыны ашыйсы килеп тора?

– Тоз кешенең баш миенә тәмәке кебек тәэсир итә. Аны активлаштырып җибәрә. Шуңа күрә тозлы ризыктан соң тагын тозлыны ашыйсы килә.

:: Соңгы арада «яшерен тоз» дигән төшенчәне дә еш ишетергә туры килә. Анысы нидән гыйбарәт?

– Безнең хәзерге туклану рационыбызда тозсыз ризык юк диярлек. Кеше көн саен ашаган ризыкның 80 процентында яшерен тоз бар. Ул, нигездә, ипи, печенье, казылык, чипсы кебек эшкәртелгән продуктларда була. Әйтик, кулләр үз иткән гамбургерда 1000 миллиграммнан артык тоз бар. Ризыкка тәм кертү өчен өстәлгән тоз без көн дәвамында кулланган тозның нибары 20 процентын гына тәшкил итә. Ит, балык, йомырка кебек продуктларның үзләрендә үк тоз бар. Әйтик, тозсыз гына әзерләнгән ит ризыкларында 3–4 грамм чамасы тоз була. Шуңа күрә тозсыз диетада утыручыларга шуларны да истә тотарга кирәк.

Киңәш-табыш

Чәч ялтырап торсын

▶ Чәчләр һәрчак коелып, яңарып торырга тиеш. Бу – гадәти күренеш. Әмма чәч коелуның да чамасы бар. Көненә 100–105 чәч бөртеге төшү норма санала.
▶ Чәчләр һәрчак матур булып ялтырап торсын өчен, иң элек дөрес тукланырга, сәламәт тормыш алып барырга кирәк. Организм даими рәвештә аксым, май һәм углеводлар белән тәэмин ителергә тиеш.
▶ Чәчләрне җылымса су белән юарга кирәк. Су температурасы уртача 37 градус булырга тиеш.
▶ Чәчне нәкъ менә сезнең баш тиресенә туры килгән шампунь белән генә юыгыз. Каты шампунь яратучыларга аны 1/1 катнашмасында су белән болгатып сөртергә киңәш ителә. Чәчкә махсус бәлзәм, сывороткалар тидерү дә файдалы.
▶ Чәч үссен өчен, аның очларын кисеп торырга кирәк, диючеләр ялгыша. Чәчнең үсү-үсмәве фәкать аның тамырына гына бәйле.

▶ Чәчләр өчен төрле майлар да әйбәт. Әмма аларны чәчнең төбенә тидермичә сөртергә кирәк. Майлар баш тиресенә эләксә, күзәнәкләр тыгылып, дерматит башланырга мөмкин.
▶ Чәчләрне зур тешле агач тарак белән көнгә берничә мәртәбә тарау яхшырак.

Үзем сынадым

АЯКНЫ КӨЗӘН ҖЫЕРСА...

Еш кына төнлә аякны көзән җыера. Соңгы арада түбәндәге ысулның файдасын күрә башладым. Иң элек табакка 2–3 литр су салып, кер сабынын эретергә кирәк. Су сөт төсенә керергә тиеш. Берәр уч чәй содасы белән аш тозын кушып, эрегәнче бутагыз. Аннары бу суга кайнар су кушарга кирәк. Шуннан соң 10 тамчы йод тамызасы. Шушы суга аякны тыгып, 15 минут котәбез. Аякларны корыткач, крем сөртеп куярга кирәк.

Казаннан КИФАЯ апагыз

Файдалы

Табын түрендә – финик

☑ Рамазан аенда өстәлебездән хөрмә (финик) җимеше өзелми. Ул яман шеш килеп чыгу ихтималын киметә, иммунитетны ныгыта. Моннан тыш финик А витамины, фосфор, натрий, кальций, калий, лактин, пантотен серкәсе һәм башка төр витаминнар, минералларга, тешләрне кариестан саклаучы фторга да бай.

☑ Финик җимешендә холестерин юк. Ул – аз калорияле җимеш. Бер финикта – уртача 23 калория. Шуңа күрә артык авырлыктан интегүчеләргә, сәламәт тормыш рәвеше алып баручыларга алыштыргысыз азык, энергия чыганагы ул. Хөрмә җимеше күзләр, нерв системасы, акыл эшчәнлеге, әчәкләр өчен файдалы, энергия һәм яхшы кәеф чыганагы булып тора.

Саклап куй!

ШИФАЛЫ КАЙНАТМА

Башта 1 кг куркәне 15–20 минут кайнатырга кирәк. Аннары шуңа 1 кг шикәр комы һәм 2 стакан кайнатмадан сироп ясап, анда куркәләрне салырга, шуннан соң тагын 30 минут пешерәсе булачак.
→ Ул кандагы гемоглобинны күтәрә, бәвел куу чарасы да булып тора.
→ Куркәләрдә антиоксидантлар бар, алар яман шешкә каршы көрәшергә сәләтле.
→ Әлеге кайнатманы теш казналыгында авырулар булган очракта, авыруга каршы торучы чара итеп файдаланырга мөмкин.
→ Ул ялкынсынуга, микробларга каршы һәм авыртуны баса торган үзлекләргә ия.
→ Нарат куркәсе кайнатмасы салкын тигәндә, бронхит, пневмония, ангина, уретрит, цистит, остеохондроз вакытында да ярдәм итә.
→ Моннан тыш ул иммунитетны күтәрә, инфаркт яки инсульттан соң йөрәк һәм кан тамырларын ныгытырга ярдәм итә.

ПОМИДОРЫҢ СӘЛАМӘТМЕ?

Помидор – иң күп һәм яратып үстерелә торган яшелчәләрнең берсе. Аны үстерү турында барысын беләбез төсле тоелса да, сезон башлангач, сорау арты сорау туып кына тора. Әле яфрагы саргая, йә бөтерелә... Болар барысы да аңа микроэлементлар җитмәүдән булырга мөмкин икән. Нәрсә җитмәвен помидорның йөзләгән сортын һәм гибридын үстереп караган бакчачы блогер Евгений Нелюбов аңлатып үтте.

ФОСФОР АЗ. Бу очракта помидорның сабаклары һәм яфраклары шәмәхә төскә керә.

Бу очракта аны суперфосфат белән тукландырырга. Ул булмаса, балык оны кулланырга була.

КАЛИЙ ҖИТМИ. Яшь яфраклары эчкә таба көпшә сыман бөтерелә, көдрәләнә, ә иске яфраклары саргая, читләре кибә. Башта яфраклар саргая, аннары яфрак читләрендә сары-коңгырт таплар барлыкка килә. Ул торган саен арта һәм яфрак тирәли каймага әверелә.

Калий сульфаты яки көл белән тукландырырга.

АЗОТКА КЫТЛЫК. Томатның яфрак читләре саргая һәм иске яфраклары коела. Кәлшә озынаеп киткән төсле була, хәлсез күренә, яфраклары ваклана. Ачык яшел, бераз сары төсмере дә булган төскә керә. Сабагы йомшара.

Бу очракта мочевина яки кычыткан төнәтмәсе кулланырга була. Тик чама белән, артыкка китсә, зыян китерүе бар.

ТИМЕР ҖИТМИ. Яшь яфракларның очларына таба төсләре ачыграк була. Яфрак җепселләре шул ук юнәлештә ачыграк төскә керә, бары читләре генә куе яшел булып кала. Шулай ук үсешендә тоткарлык сизелә, чәчәкләре ваклана.

Тимер купоросы белән эшкәртергә.

КАЛЬЦИЙ АЗ. Яфраклары куырыла, ямьсезләнә. Помидорларда черек барлыкка килә.

Кальций селитрасын яки кальций хлоридын яфракларына сибәргә.

vk.com

ХӘЛСЕЗ ЯФРАКЛАР ӨЧЕН «ТӘМЛҮШКӘ»

10 л суга 10 г чи чүпрә, 4 аш кашыгы шикәр комы салып болгатырга. Аны 1–2 көн тотып әчетергә. Аннары бер өлеш эремәгә ун өлеш су салып, помидор төпләренә сибәргә. Бу ысулны кулланганнан соң яфраклары яшелләнеп, помидор үзе ныгып китә. Әлеге катнашмага бераз гына йод салып сибү дә файдага булыр. Бу – бердән, тукландыру булса, икенчедән, корткыч бөҗәкләр һәм гөмбәчекләрдән саклау чарасы да.

Киңәш

Бүләк итте миңа орхидея

Ел әйләнәсе чәчәкләре белән куандыра торган орхидея бүләк итсәләр, дөрес тәрбияләмәү аның үлеменә китерергә мөмкин. Түбәндәге кагыйдәләрне истә тотканда, яраткан гөлегез бик озак күзегезне һәм күңелегезне иркәләр.

- Бүләккә орхидея алганнан соң, аның яфрак, тамыр һәм туфрагына игътибар итегез. Корыган тамырлары булса, кисеп ташларга һәм фунгицид (гөмбәчекләргә каршы препаратлар) белән эшкәртергә кирәк. Туфрагын алыштырып, тамырына һава керерлек итеп, керамик савытка утыртыгыз.
- Су сибү туфрак дымлылыгына бәйле. Аңа кайнатып суытылган яки бераз лимон кислотасы салынган әчкелтем су сибү дә файдага. Атнага бер тапкыр орхидея утырган чүлмәкне су салынган чиләккә утыртып алырга киңәш ителә. Сабактан чыккан тамырчыкларына суны пульверизатор белән сибәргә киңәш ителә.
- Гөлне дымлылык күп булган аш бүлмәсендә тотыгыз, чөнки ул дым ярата.
- Аңа яктылык күп кирәк, әмма җәй көне туры кояш нурларыннан саклагыз, артыгы зыянга булуы бар.

Бакчачыга

Җиләк уңа

Түбәндәге хәйлә бакча җиләгенең уңышын арттырырга ярдәм итә. Моның өчен 10 л суга 40 мл нашатырь спирты салып, төбенә сибеп чыгарга кирәк. Бу ысул уңышны арттырудан тыш, җиләкне авырулардан һәм корткыч бөҗәкләрдән дә саклый.

Тәмле булсын!

БИК ТӘМЛЕ БЕЛЕН

Рәфилә ШӘМСЕТДИНОВА рецепты

1 литр сөт (1:1 су+сөт ярый, мин шулай салдым), 3 йомырка, 1 чәй кашыгы тоз, 2 чәй кашыгы шикәр комы, кашык очында гына сода (серкә белән сүндерәсе түгел), 100 г (ярты стакан) сыек май, он. Барысын бергә кушып болгатасы, беленнең сере – онның күләмендә. Куерып китсә, кайнаган су өстәргә. Табаны майлап пешерсәң, тишекле була, майламасаң да ярый. Гап-гади рецепт булса да, гел яхшы чыга, ябышмый һәм юка да була.

КОРТ ЯСАУ ЫСУЛЫ

Гөлнара ГАЛИМУЛЛИНА рецепты

Калын төпле савыт алырга кирәк. Сөт төпкә утырмасын, көймәсен өчен, савытны үсемлек мае салып кыздырып алам. Бераз суынгач, шуңа 3–4 л сөт салам, ул кайнап чыгар алдыннан 5–6 кг эремчек кушам. Болгата-болгата, кызгылт төскә кергәнче кайнатырга кирәк. Аннан 200–250 г атланмай, 0,5 л йорт каймагы өстим. Булса, катык та салырга мөмкин. Азактан тәменчә шикәр комы салам. Шикәр комын суы беткәндә генә салырга кирәк, чөнки иртә салганда, корт катып китә. Корт әзер булганчы, шулай 4–5 сәгать кайный.

Белеп тор!

КӘБЕСТӘ ПЕШЕРҮ СЕРЕ

Голубцы яратучыларның күпчелеге кәбестә пешереп мәшәкатьләнүне бик өнәп бетерми. Чөнки вакытны күп ала. Ә минә аны кыска дулкынлы мичтә бик ансат пешереп була икән.

Моның өчен уртача зурлыктагы кәбестәне кыска дулкынлы мичкә тыгын, 10–15 минут пешерергә. Аннары аны алып, өстенә краннан салкын су коярга. Шулай эшләгәндә кәбестәнең яфраклары бер-берсеннән бик җайлы аерыла. Авыррак аерыла башлагач, аны тагын кыска дулкынлы мичкә тыгып аласың һәм алда язып үтелгәнчә кабатлыйсың. Болай үзегезгә кирәк кадәр пешереп, кәбестәнең артып калган чи өлешен башка ризык әзерләү өчен кулланырга мөмкин.

ДӨРЕС ТУҢДЫРАСЫҢМЫ?

Пешекче Зөлфия ИДРИСОВА камыр ризыкларын туңдыру буенча киңәшләрен бирде.

✓ Камыр ризыкларын тимер подноста яки формада туңдыру яхшы, анда ризык тизрәк катачак.

✓ 6–12 сәгать узганнан соң, каткан ризыкларны савытларга яки пакетка салып куярга кирәк. Юкса камырның өсте кибеп китәчәк һәм пешергәндә ярылачак.

✓ Туңдырылган камыр ризыгын пешерер алдыннан, алып, бүлмә температурасында эретергә кирәк.

✓ Мичкә тыгар алдыннан, туңдырып җебетелгән камыр ризыклары өстенә бераз гына су бөркегез. Пешкән вакытта да 1–2 тапкыр шулай су бөркеп алыгыз.

✓ Туңдырылган камыр ризыкларының пешергәндә бәрәңгесе каралмасын өчен, сары эчле бәрәңге кулланырга кирәк.

Исеңдә тот!

АЛТЫН ЧИСТАРТАБЫЗ

Зур булмаган савытка җылы су, савыт-саба юа торган сыеклык өстәп, шуңа 15–20 минутка алтын бизәнү әйберләрен салып куегыз. Аннары теш щеткасы ярдәмендә аларны акрын гына ышкып юарга кирәк. Җылы суда чайкап алырга һәм микрофибра салфетка белән кызылап корытырга. Кәгазь яки башка тупас материаллар белән сөртмәгез, чөнки зәркән эшләнмәдә тырналган урыннар барлыкка килергә мөмкин.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

УЙЛАП ӘЙТӘСЕ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһның ачуын үз өстегезгә алып, җәһәннәмнең интегүләрен үзегезгә якынайтып, бер-берегезгә карата ләгънәт, каргыш кылмагыз», – дигән. Бу сүзләрнең ни дәрәҗәдә хак булуын һәркайсыбыз аңлый. Әмма көндәлек тормышыбызда моның нәкъ киресен чагылдырган мисаллар да шактый очрый. Авыздан чыккан бер кәлимә сүз аркасында каргышка дучар булмас өчен ни эшләргә? Ләгънәттән ничек сакланырга?

islam.ru

«Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Ансар хәзрәт МИФТАХОВ каргышка бәйле сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Хәдисләрдә каргыш, рәнҗеш турында ниләр әйтелә?

– Каргау, рәнҗү – шәригатебез буенча тыелган гамәлләрнең берсе. Адәм баласы, нинди генә авырлыкка дучар булса да, һәрвакыт сабырлык күрсәтеп, шушы мәшәкатьләргә сабыр булырга тиеш. Ул түземичә, кемгәдер бәддога кылып, кеченә генә явызлык өчен дә каргап, начарлык теләү шәригатебездә гөнаһлы гамәлләрдән санала. Хәтта пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешегә каргыш, бәддога кылмагыз. Ул каргыш күккә менәр – күк кабул итмәс, җиргә төшәр – җир кабул итмәс. Кем шушы бәддоганы, шушы каргышны теләде, шуңа үзенә әйләнеп кайтыр», – ди. Шуңа күрә әгәр кеше башка берәүне каргый икән, аның шушы каргышы, ике арада йөреп, үзенә әйләнеп кайта. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә: «Кешегә изгелек теләсәң, тиз ирешер, явызлык теләсәң, акрын гына ирешер», – ди. Шуңа күрә кешегә яхшы теләсәк, ул хәерлерәк һәм дөресрәк була. Дога кылганда хәтта яндагы фәрештәләр дә: «Амин, үзең дә шул теләккә иреш», – дип утырыр, ди.

:: Ни өчен, каргыш ике яклы була, дилә́р?

– Моны болай дип аңларга кирәк. Каргышның берсе ниндидер бер сәбәп аркасында, икенчесе сәбәпсез, нахакка әйтелә. Әгәр кеше нахакка каргый икән, бу кешенең догасы кабул булмый һәм ул аның үзенә кире әйләнеп кайтачак. Әгәр кеше билгеле бер сәбәп аркасында бәддога кыла икән, ул дога кабул булырга да мөмкин. Пәйгамбәребез дә: «Рәнҗетелгән адәмнең догалары кабул булыр», – ди. Телен тыймыйча, адым саен кешеләрне каргап йөрүчеләр бар. Бу, әлбәттә, бик зур гөнаһлардан санала. Күпләр моны аңлап бетерми. Үз каргышы үзенә әйләнеп кайткач та төшенми ул аңа.

:: Каргыш җиде буынга кадәр төшә, диюләре дөресме? Ни өчен?

– Юк, каргыш җиде буынга төшә алмый. Ник дигәндә, һәр чорның – үз кешеләре. Без борынгы әби-бабаларыбыз өчен хәзерге вакытта җавап бирә алмыйбыз. Аллаһы Раббыбыз «Бәкарә» сүрәсендә: «Ул буын яшәп китте. Алар сезнең гамәлләрегез өчен җавап бирмәс», – ди.

:: Үсемлек, хайваннарның да каргышы төшә аламы?

– Үсемлекләрнең каргышы төшү-төшмәве билгесез. Әмма аларның тәсбих әйтү мөмкинлеге бар. Ягъни үсемлекләр, агачлар үзләрен утырткан, чәчкән, су сипкән кешегә тәсбих әйтеп, Аллаһы Тәгаләдән аның гөнаһларын гафу итүне, әҗер-савап бирүне сорап утыралар. Хайваннарга килгәндә, пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Бер хатын-кыз мәче сәбәпле җәһәннәмгә керде, зиначы хатын-кыз эт сәбәпле җәннәткә керде», – дигән. Хайваннарның да рәнҗеше төшә. Кыямәт көнендә хайваннардан да сорау алыначак. Алар, телгә килеп, хуҗасы, аның эшләгән гамәлләре турында сөйләячәк. Хуҗасының аңа карата кылган гамәлләрен сөйләгәннән соң, ул хайваннар тузанга, туфракка әйләнерләр, ди. Гыйлем алучы бәндәләргә хәтта хайваннар да, кошлар да, балыклар да дога кылып торырлар, дигән гыйбарә яши.

:: Кешене каргап, соңрак бу гамәлең өчен үкенсәң, ни эшләргә?

– Аллаһы яралткан нәрсәне каргап дога кылу – начар гамәл. Кемдер сине гаделсезгә рәнҗеткән икән, аны Аллаһның хөкеменә тапшырырга кирәк. Пәйгамбәребез: «Кемдер үзен рәнҗетүчене каргап дога кылса, кыямәт көнендә рәнҗетүченең рәнҗетелгән кеше алдында өстенлеге булыр», – ди. Шуңа күрә каргау мәсьәләсендә бик сак булырга кирәк. Нинди генә гөнаһ кылсак та, без иң беренче чиратта Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенергә тиешбез. Тәүбә намазлары укып, Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларны кичерүен сорыйбыз икән, Аллаһы Тәгалә һичшиксез гафу кылыр.

:: Кайчак кеше кирәксә-кирәкмәсә дә: «Мин сиңа рәнҗим», – дип әйтеп куя. Күпләр моны үпкәләгәнне белдерү өчен бер сүз итеп кенә кабул итә. Чынлыкта «рәнҗим» дигән сүз мәгънә ягыннан шул ук «каргыйм» дигән сүз белән бер үк дәрәҗәдә бит? Димәк, кеше, үзе дә белмәстән, сине каргаган булып чыгамы?

Аның фикеренчә, совет заманындагы кебек урам себерүче, слесарьларга торак бирү системасын кабат кайтарырга кирәк. Шулай ук хезмәт хакын да яхшыртмыйча булмый. Болай булса, биш елдан урам себерергә кеше калмаска мөмкин.

Әле ярый пенсионерлар бар...

Шәһәрләрдә генә түгел, районнарда да кытлык бар. Арча шәһәре идарәче компаниясе директоры Илгиз Әлиев белдергәнчә, шәһәрдәге күпкатлы йортларга 26 дворник хезмәт күрсәтә. Кемдер берничә йорт тирәсен җыештыра. Бүген ике хезмәткәр кирәк. Оклад – 20 мең сум. Премияләр дә түләнә.

– Мондый стандарт турында ишетмәдек. Таләпләрне катгыйландырырга кирәкми. Урам себерүчеләр болай да җитми. Булганы да – пенсионерлар һәм инвалидлар. Бүген җылылыкта алар белән җәйге режимга күчәбез дип сөйләштек. Балалар мәйданчыкларына карата игътибарны арттыруны сорадым. Ватылган нәрсәләр булса, шалтыратыгыз, дидем. Үләнне үзебез бригада белән чабабыз, су сибәсе җе юк. Алардан бары чисталык кына сорала, – ди Илгиз Әлиев. – Җыештыручылар кайдан табаргамы? Сау-сәламәт, яшь кешеләрнең дворник буласы килми. Ул башка җирдә эшләп, ике-өч тапкыр күбрәк хезмәт хакы ала. Иртә белән күзеңне ачтыңмы, акча кирәк бит. Эшләгән пенсионерның акчасы индексацияләнсә, шактые бу хезмәткә тартылыр иде дип уйлыйм. Индексация бармагач, аңа кызык түгел.

Фикер

Дмитрий РОМАНОВ, «Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры:

– Хезмәт хакын тиешле таләпләргә туры китергәч кенә, һөнәри стандартлар кертергә кирәк. Казанда 500ләп дворник җитми икән, республиканың башка районнарында нинди хәлдәр? Хезмәт хакы аз булгач, эшләүчесен табу авыр. Әле болай да кеше таба алмыйбыз. Монда тагын стандарт кертмәкчеләр. Аны идарәче компания белгечләренә, ТСЖ рәисләренә кертергә кирәк. Аларның йорт белән идарә итүдә белемнәре җитми. Йә инде яхшы хезмәт хакы түләсеннәр. Идарәче компанияләр, түләү җыештыру мәйданына бәйле, диячәк. Йорт саны азрак булган саен, акча да кимрәк. Кайберләренең эш хакы 5–6 мең сумнан башланырга мөмкин. Акча шул йортта яшәүчеләр хисабына түләнә. Аны пирчәткә, махсус кием, кирәк-ярак алырга һәм башка чыгымнарга да тотарга кирәк. Һөнәри стандартка кем өйрәтер? Урам себерүче әле бит укырга да тиеш. Ә ул кайда өйрәнәчәк? Бу идеягә уйлап тотынырга кирәк. Конкретлык юк.

СУМНЫҢ САНЛАШУЫ

ЯҢА ВАЛЮТАНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ НИДӘ ҺӘМ АНЫ НИЧЕК КУЛЛАНЫРГА?

Россия банкларында эксперимент рәвешендә цифрлы сум сынала. Гади итеп әйтсәк, илдәге өченче валюта, яңа түләү чарасы бу. Тагын да гадиләштергәндә, кәгазь акча белән картаның гибриды. Әлегә сынауда берничә банк кына катнаша. Техник якларын барлаганнан соң, мондый төр сумны куллану мөмкинлекләрен киңәйтәчәкләр.

Бәйсез финанс консультанты Шамил МУТАЛОВтан яңа валютаның үзенчәлекләре хакында сораштык.

Цифрлы сум – ни ул?

Цифрлы сум – илдә гамәлдә булган акчаның өченче төре. Ул картадагы акчабызга охшаш, ләкин башкача эшләячәк. Төп аерма шунда: ул акча янчыгында да, банк счетларында да түгел, ә Үзәк банк әзерләгән платформада – «цифрлы янчык»ларда сакланачак. Бу акча белән банкларның мобиль кушымталары аша түләргә мөмкин. Кушымтада моның өчен «цифрлы сум» дигән счет булачак. Акча җибәрү өчен физик яисә юридик затның да цифрлы счеты булуы шарт.

Нәрсә өчен кирәк?

Гадәти акча кебек куллану өчен. Хезмәтләр, товарлар өчен түләргә, кыскасы, моңа кадәр валютаны ничек кулланса-гыз, алга таба да шулай эшләргә мөмкин.

Беренчедән, мондый сум бернинди банкка да бәйле түгел.

Икенчедән, акча ниндидер билгеле бер банкта сакланмый. Шуңа күрә җаваплылыкны Үзәк банк үз өстенә ала. Теге яисә бу банк банкрот булып танылырга мөмкин, ә Үзәк банкның банкрот булу ихтималы минималь. Шуңа да бу акчаны саклау җәһәтеннән куркынычсызрак.

Өченчедән, исәп-хисап башкару тизләге. Ул бик тиз булачак. Бу юридик компанияләр өчен аеруча мөһим. Хәзер акча күчерү еш кына берничә көнгә сузылырга мөмкин. Цифрлы сум очрагында акча күчерү эше бик тиз һәм тәүлек әйләнәсе гамәлдә булачак. Тагын бер мөһим ягы: зур суммалар күчергән очракта комиссиянең кечкенә булуы.

Дүртенчедән, цифрлы сум куркынычсыз килешүләр төзү өчен кирәк. Бу инде күбрәк зур оешмалар өчен отышлы. Гадәти килешүләрдән аермалы буларак, смарт-килешүләрдә (компьютер программасы рәвешендә язылган килешү) кеше факторы тулысынча юкка чыга. Программа ничек язылган, шулай үтәләчәк тә. Ягъни анда хата бар икән, ул нәкъ менә программа әзерләнгән вакытта барлыкка килгән, һич кенә дә килешүне үтәгән вакытта түгел.

Ничек кулланырга?

Коммерциячел банкның мобиль кушымтасында мобиль цифрлы янчык ачарга кирәк. Аңа акча салып тору ысуллары бик гади: банк аша, касса аша, башка счеттан күчереп. Комиссия минималь булачак, шуңа күрә кемнең нинди банк клиенты булуы мөһим түгел. Цифрлы сумны «тере» акчага әйләндереп һәм банкоматтан алып та була. Цифрлы сум 1 сумга тигез. Димәк, цифрлы сум да инфляциягә дучар дигән сүз.

Кайчан гамәлгә керәчәк?

Апрельдә бу система сынау үтә. Анда катнашу өчен 13 зур банкны сайлап алдылар. Исемлеге билгеле. Бу банклар цифрлы сумны сынап карагач, аны киң кулланышка кертмәкчеләр.

Гамәлгә кертү нәрсәне аңлата?

Дәүләт барлык акчаны үз контроленә алачак, күпме акча барлыгын белеп торачак. Хәер, бу инде – билгеле факт. Салым хезмәте дә нинди исәп-хисап счетлары-быз барлыгын, матди мөмкинлекләребез турында белеп тора бит.

Тагын бер проблема цифрлы сум өчен Үзәк банк чыгарган платформаның эшенә бәйле. Аңа киберһөҗүм булса, мошенниклар кулына эләксә? Бу, билгеле, шикләндерә. Андый куркыныч гел бар. Цифрлы сум мошенникларга бәйле хәлне үзгәртә алмас анысы. Тик шулай да, акча кырыгалдарларга күчерелгән очракта, ахыргы кулланучының кем икәнен күреп булыр иде. Хәер, аның да фиктив зат булуы мөмкин.

«Выберу.ру» хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, Россия халкының 38 проценты цифрлы сумның ни икәнен, аның нәрсә өчен билгеләнгәнен аңламый. Ә 28 проценты аңа ышанмый икән. Шуңа күрә аны кулланудан баш тартырга җыена. 34 проценты яңа түләү чарасын кулланып карарга риза.

Тискәре яклары бармы?

Цифрлы сумны гамәлгә кертүдән коммерциячел банклар зыян күрәчәк. Ник дигәндә, бу банклар акча күчергән өчен комиссия ала иде. Ә хәзер комиссиянең бер өлеше Үзәк банкка китәчәк. Димәк, бу банклар күпме акчасын югалтачак.

Цифрлы сум Үзәк банкта сакланачак, дидек. Димәк, коммерциячел банклар алардан файдалана алмаячак. Әйтик, кредит бирә алмаячак.

Тагын әле конкуренция артачак дигән сүз. Бәлки әле банклар нинди дә булса яңалык уйлап табар һәм бу безгә – кулланучыларга файдага гына булыр.

Уңай яклары нидә?

Дәүләт бюджет акчасы кая тотылганын күреп тора алачак. Акча каядыр югалып, эленеп калмаячак. Халыкара акчалата исәп-хисап эшләрен башкару өчен цифрлы сум – яхшы ысул. Дәүләт бу системаны, әйтик, Кытайдагы юань системасы белән җайлаштыра алса, яхшы булачак.

Бер-бер хәл булса, нишләргә?

Үзәк банк, мондый проблемаларны хәл итү өчен, махсус бүлек булдырырга тиеш. Әле болар барысы да – сынау хәлендә.

Цифрлы сум – криптовалютамы?

Криптовалюта Үзәк банк акчасыннан бик нык аерыла. Криптовалютаның бердәм эмитенты (кыйммәтле кәгазьләр, акча һәм башка активлар чыгаручы оешма), шулай ук кулланучы хокукларын яклау гарантиясе юк, аларның хакы да җитди үзгәрүләргә дучар. Цифрлы сум – Үзәк банкның җаваплылыгында, цифрлы технологияләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла һәм аның криптовалюталарга бернинди дә катнашы юк. Бу – фиат валюта (хөкүмәт чыгарган акча формасы, ул законлы түләү чарасы дип игълан ителгән), ягъни аның тотрыклылыгын дәүләт Үзәк банк ярдәмендә тәэмин итә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЦИФРЛЫ СУМНЫ КУЛЛАНУ ИНСТРУКЦИЯСЕ

1

Цифрлы акча янчыгы булдырырга.

2

Мобиль, интернет-банк, исәп-хисап счетыннан акча күчерергә.

3

Башкаларга акча күчергәндә (физик һәм юридик затлар), цифрлы акча янчыгы иясенең телефон номерын күрсәтергә.

4

Цифрлы сум белән хезмәт һәм товарлар өчен түләргә. Түләү өчен QR-код кулланырга.

5

Бер үк кешедә берничә банк картасы булырга мөмкин. Әмма цифрлы акча янчыгы бер генә була ала! Цифрлы сум белән операцияләрне интернетсыз да башкарырга мөмкин.

1 СУМ = 1 ЦИФРЛЫ СУМ

ВАЛЮТАЛАРНЫҢ ОХШАШЛЫГЫ ҺӘМ АЕРМАСЫ

	«Тере» акча	Акчалата булмаган исәп-хисап (безналичный расчет)	Цифрлы сум
Нинди була?	Банкнота, тимер акча	Счеттагы акча	Цифрлы код
Кем чыгара?	Үзәк банк	Коммерциячел банк	Үзәк банк
Ничек түләргә?	Офлайн	Онлайн	Онлайн һәм офлайн
Кайда сакларга?	Кулда, банк ячейкасында	Банкта, кертемдә, туплау счетында	Цифрлы акча янчыгында (Үзәк банк платформасы нигезендә)
Ничек сакларга?	Процентларсыз	Процентган керем алырга мөмкин	Процентларсыз

КАЙДА НИЧЕК?

Цифрлы валюта гамәлдә: Нигерия, Кариб бассейнына кергән кайбер илләрдә.
Сынау рәвешендә гамәлдә: Көньяк Африка Республикасы (ЮАР), Таиланд, Малайзия, Сингапур, Кытай, Мьянма, Россия, Украина, Швеция, Казахстан, Согуд Гарәбстанында.
Цифрлы валютаны булдыру этабындагы илләр: Һиндстан, Индонезия, Германия, Франция, Испания, Италия, Иран, Төркия, Канада, Австралия, Бразилия.
Гамәлгә ашырудан баш тарткан яисә проектны туктатып торган илләр: Аргентина, Уругвай, Эквадор, Азәрбайҗан, Финляндия, Дания, Мисыр, Сенегал, Корея Халык Республикасы (КНДР).

ҖИДЕ ЕЛДА – ҖИДЕ ХӘСРӘТ

Түзсә дә түзә икән йөрәк. Башкача мөмкин дә түгел. Яшәргә кирәк. Чирмешән районының Түбән Кәминкә авылында яшәүче, тиздән 60 яшен тутыручы Рәмзия Гыйрфанова үз-үзен әнә шулай итеп юата. Язмыш аны бик озак сыный. Җиде елда җиде газиз кешесен җирләргә туры килә аңа. Әни дип өзелеп торган кызлары, кияүләре хакына ул сынауларны күтәрә ала.

– Әле хәзер дә төрле чакларым бар, сеңлем. Кайбер көнне үлеп тә алам, тереләм дә. Ачы хәсрәтләрем исемә төшеп егып салган көннәр дә бар. Хәзер инде еламаска да өйрәнеп киләм. Еллар узган саен, күңелдәге яралар да әкренләп төзәлә кебек, – ди Рәмзия апа.

Сагыш җиле алар ишеген 13 ел элек шакый. Март аеның 16сында була бу хәлләр. Ул көнне кунакка кайткан студент улы Ришат, апасын, җизнәсен, аларның бер яшьлек кызларын утыртып, юлга кузгала. Әлмәткә китеп барышлары була.

– Балаларымның авариягә очраганын кызым Гөлшатка шалтыратып әйткәннәр. Аның елый-елый кем беләндер сөйләшкәнен тәрәзәдән күреп чыктым, миңа сиздермәде. Бу хәлләрне ирем дә белгән булган инде. Сорый торгач, балаларның авариягә эләгүләрен әйттеләр. Мин тизрәк кызым Ландышка шалтыраттым. Ул телефонны алгач, тынычландым. Үз әнием килеп, дөресен әйтте: улым Ришат белән кияү Рамил үлгән, оныгым Әлфинурның да хәле бик авыр икән. Шул чакта бар дөньям караңгыланды. Яшәвемнең мәгънәсен югалттым, – дип сөйли Рәмзия апа.

Икенче көнгә дүрт кыздан соң көтеп алган Ришатын алып кайтып җирлиләр. Бер көннән кодагыйлары йортына Рамил белән Әлфинурны алып кайталар. Бала белән атаны икесен бер кабергә куялар.

– Бу вакытта Ландышымның хәле авыр иде. Ул кайта алмады, хастаханәдә калды. Рамил белән Ландышның өйләнешкәннәренә дә ике ел гына иде. Улым Ришат та бик матур хыяллар белән яшәде. Укуын бетергәч, армиягә барасы, аннан кайткач, өйләнәсе иде. Авылда калырга теләде. Тик сабыемның гомере генә озын булмаган. Бернишләп тә булмый. Аллаһы Тәгалә үзе бирә, үзе ала икән, – ди Рәмзия апа. – Өч айдан Ландышым култык таяклары белән кайтты. Икәү бик еладык инде. Ул миңа күрсәтми, мин аңа. Өзгәләнде йөрәкләребез. Икебез дә бала хәсрәте кичердек. Әле кызым яраткан ирен дә югалтты. Аңа бигрәк авыр иде ул чакта. Әмма ул бирешмәде. Баламның савыга башлавын күреп сөенә идем инде. Тик кинәт кенә аягы бозыла башлады. Тагын хастаханә юлын таптады. Башта Әлмәттә, аннан Казанда ятты. Табиблар аны коткара алмады. 6 ай дигәндә, кызымны да югалттык.

Кадрия Гамирова фотосы

Ландышны югалту бөтенләй бетерсә дә, алар ничек тә яшәр көч таба. Кызларның бер елын уздыргач, бар сабырлыкны җыеп, Хөсәен абый белән Рәмзия апа Гөлшатларын кияүгә бирәләр. Матур мизгелләр белән яши башлыйлар. Тик әле сынау бетмәгән икән. Озак та үтми, ире Хөсәен абый да урынга ята. Хәтере начарая, сәламәтлеге какшый. Рәмзия апа ирен табибтан-табибка йөртә. Кулдан килгәнчә ярдәм итә. Ирен кайгыртып йөргәндә, әтисе урынга ята. 2014 елның гыйнварында – әтисен, декабрьдә 57 яшен дә тутырмаган ирен җирли. Ә өч елдан әнисе дә вафат була.

– Газизләремне озаткандa кычкырып еламадым да. Яңәсе, мөселманнарга алай ярамый. Бар хәсрәтемне эчемә җыйдым. Үксеп-үксеп, ярсып, бер елыйсы калган да бит! Әнә шул эчкә җыю харап итә язды мине. Депрессиягә бирелдем, – ди Рәмзия апа. – Ничек юләрләнмәгәнмендер инде. Бу хәсрәтне ничек күтәрим икән, дия идем. Кызларыма, кияүләремә рәхмәт. Бик кайгырттылар. Авырып китмәсен дип кенә яшәделәр. Кая гына йөртмәделәр. Табиб та калмады, өшкерүчеләр дә. Шул балаларым ярдәме белән мин яңадан яши башладым. Әгәр әни исән калса, корбан чалдырыр идек, дип нәзер дә әйткән булганнар. Менә шуннан чамалагыз инде хәлләремне.

Аңа кияүләрнең дә алтыннары эләгә. Ишектән үк, нәрсә эшлик, дип керәләр икән. Бер кызы – Чирмешәндә, икенчесе Әлмәттә тора. Өченчесе каршы якта гына яши. Авылдагы кияүсез бернишли алмыйм, ди Рәмзия апа. Таякның юан башы күбрәк аңа төшә икән.

Рәмзия апа намазга да баскан. Атнасына ике тапкыр мәчеткә укырга йөри. Сабырлык, күңел тынычлыгын догалар белән тапкан ул. Дога өмет итүчеләре күпме бит! Әнә кичә генә Ришаты төшенә кергән. Әтисе белән бергә кайтканнар, имеш. Улы Рәмзия апага карап торган да: «Әни, әле сиңа 60 яшь бирeп булмый», – ди икән. «Бик шатланып уянып китем», – ди Рәмзия апа.

Дөрестән дә, әле аңа 60ны бирeп булмый. Үзе дә, күңел 18дә, дип шаярта.

– Мин кияүгә килгәндә, каенанам 65 яшендәге бик олы карчык кебек иде. Әле без картаерга ашыкмыйбыз. Әчтә ут янса да, күрсәтмибез, матур яшәргә тырышабыз. Борчуларымны онытыр өчен, авылыбыздагы «Ак калфак» җыр коллективына йөрим. Кызлар белән очрашып бер сөйләшү дә күңелне күтәрә, – ди ул. – Авылыбызда бер кайгысыз берәү дә юк. Кодагыем да хәсрәт утында янып яши. Башта киявем Рамилне, 6 елдан икенче улын җирләде. Шулай бер-береңне юатып яшисең инде.

Рәмзия апа быел эшкә дә урнашкан әле. Клубтагы идән юучы декретка киткәч, аны алыштырып тора икән. Әле мәчеттә, әле җыр-биюдә, әле кул эшләре белән йөри. Инде идән дә юып кайткач, моңсуланырга вакыты калмый. Авыл җирендә эшнең дә бетәсе юк. Атна ахыры җитсә, балалары кайтып сөендерә. Берүзенә 8 оныгы бар аның. Менә кайда ул байлык!

– Әле ярый күп бала тапканмын дип сөенәм. Икәү генә булган булсалар, нишләр идең. Үз картлыгымны уйлаганмын икән, – ди ул. – Бер киңәшем бар: баласын югалткан анага юату сүзләре әйтмәгез. Елама, димәгез. Еласын күңелен бушатып. Ни генә әйтсәгез дә, ул ананың хәлен аңлый алмассыз. Мин хәзер андыйлар янына барам да дәшмим. Әчемнән генә Аллаһы Тәгаләдән: «Бу бәндәгә сабырлык бир», – дип сорыйм.

ӨМЕТНЕ ӨЗМИК!

Күп еллар «Барс-Медиа» компаниясе белән хезмәттәшлек иткән, бик күп артистларның клипларын, концертларын төшергән видеооператор – 35 яшьлек Фәнис Җиһаншин авыр хәлдә. Аның хатыны Венера иренең сәламәтлеге өчен барысына да әзер. Алар бүген икесе дә Мәскәүдә. Казан табиблары бернинди өмет бирмәсә дә, андагылар Фәнисне кабул иткән.

– Иремнең хәле кинәт начарайды. Бернидән дә зарланганы булмады аның. Авырганы да юк иде. Яңа елдан соң гел, хәл юк, диде. Ашый да барып ята. Йоклады да йоклады. Тазарып та китте. Минем генә түгел, якыннарымның да күңеленә борчу керде. Кайчак сөйләшкәндә буталып куя иде. Нидер барын сизендек. Тикшеренер өчен табибка килдек. 27 гыйнвар иде ул, – дип сөйли Венера. – Табиблар МРТ узарга киңәш иттеләр. Нәтиҗәсе сөендермәде. Табиб, үземне генә чакырып, Фәнистә яман шеш икәнен җиткерде. Ул чакта бик авыр булды. Әмма үземне кулга алдым. Ике балабыз хакына ничек тә бу авыруны җиңәрбез дип уйладым. Фәнис башта белмәсә дә, соңрак үзендә мәкерле чир икәнен аңлады.

Хастаханәдән кайткач, Фәниснең хәле тагын да авыраеп китә. Бераз җиңел булмасмы дип, уколлар ясый башлыйлар. Шуннан соң күзгә күренеп яхшыра башлый.

– Тикшеренүләр узар өчен МКДЦда ятып чыгарга дигәннәр иде. Әмма температурасы югары булу сәбәпле, анда алмый тордылар. Шулай итеп, шактый вакытны югалттык. Әмма соңыннан табиблар барыбер салды аны. Температурасын да төшерделәр. Хәле генә яхшырмады... – ди Венера. – Үзебез генә күтәрә алырлык чыгым түгел бу. Шуңа да квота сорап, министрлыкка бардым. Документларын Мәскәүгә җибәрәбез дигәннәр иде. Ни сәбәпледер язулар китми яткан. Үзебез машина белән илтеп бирдек.

Хәзерге вакытта Фәниснең хәле бик авыр. Ул янындагыларны аңламый. Бар өмет – табибларда. Төгәл диагноз куяр өчен тикшеренергә кирәк. Ә аннары катлаулы операция ясап, шешне алырга тиешләр. Аннары инде бар да элеккечә булыр кебек. Фәниснең гаиләсе шулай дип яши. Әмма хыялларны тормышка ашыру өчен акча кирәк. Шуңа да Фәниснең якыннары ярдәм сорый.

Булышырга теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары: хатыны Венера Сәлимҗан кызы Җиһаншина исемендәге Саклык банкы картасы **8-937-288-75-70** номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТУФАН ИМАМЕТДИНОВ:

«МИНЕ ТӘНКЫЙТЬ СЫНДЫРА АЛМЫЙ»

Соңгы вакытта зур игътибар үзәгендә булган театр ул – Тинчурин театры. Анда – бәхәс, анда – фикер алышу, яңалыкка омтылу. Бу арада тинчуриннылар янә спектакль-тәҗрибә әзерләп ята. Андагы мохит, тәнкыйтькә караш, үзгәрешләр һәм үзгәртүләр турында театрның баш режиссеры Туфан ИМАМЕТДИНОВ белән сөйләштек.

«Татар-информ»

:: Кешегә ул эшләгән бина, андагы мохит тәэсир итми калмый. Ирекле режиссерга Тинчурин театры ничек тәэсир итте?

– Мондагы мохит, вазгыять мине нычытты. Яшерен-батырын түгел, яңа җирдә төрле хәлләр була. Алар белән нормаль хәлгә әйләндергәнче эшләргә туры килә. Мин килгәнче, Тинчурин театры коллективы шактый вакыт баш режиссерсыз эшләде. Ә аңа кадәр, өлкән буын актерларны исәпкә алмаганда, күбесе Рәшит абыйда (Рәшит Заһидуллин – Тинчурин театрының элеккеге баш режиссеры. – **Авт.**) укыган. Шуңа күрә аларга психологик яктан яңа кешегә ияләшү авыр булды һәм миңа әнә шул як белән дә эшләргә туры килә. Кайберләре яңа юнәлешкә күнегә, алар аны ошата башлады, ә кайберләре әлегә сыный, күзәтә. Мин биредә ел ярым һәм без коллектив белән бер-беребезне кабул итү юнәлешендә эшлибез. Бу табигый, алар Рәшит абый белән 30 елга якын эшләгән, ә шулкадәр озак вакыт бер кеше белән эшләгәч, икенче кешегә күнегү бик авыр.

:: Өстәвенә Тинчурин театрына читтән режиссер кермәде, дип әйтсәк тә була.

– Рәшит абыйның укучылары спектакльләр куйды инде…

:: Ә коллективның төркем-төркем булуы эшкә комачауламыймы?

– Театр директоры Фәнис Мөсәгыйтов әйтмешли, элек монда алты төркем булган, хәзер ике генә калды: кабул итүчеләр һәм итмәүчеләр.

:: Үзеңә игътибар артык күп дигән тәэсир калмыймы?

– Ул игътибарны сорап та алмыйм инде югыйсә. Мөгаен, җәмгыятькә пар чыгарып бушана алырлык фигура кирәктер. Ә икенче яктан, сәхнәгә шәрә хатын-кызның чыкканы юк, тыелган темалар күтәрелми, гомумән, бәхәс уятырлык сәбәп юк. Ә бит башка театрларга күз салсак, аларда мин санап киткән күренешләр бар, ә бәхәс чыкмый. Без исә бөтен кеше кабул иткән әдәби әсәрләргә алынабыз һәм тавыш чыга…

:: Димәк, түбәгез ныклы түгел. Барлык мәгънәдә дә.

– Юк, түбәбез әйбәт, бу – тарихи бина. Үзебезнең «түбә»ләр дә китмәгән әле.

:: Син нинди режиссер?

– Гадел булу авыр, ләкин булдырып булырлык гамәл. Һәрхәлдә, гаделлеккә омтылырга кирәк. Шуңа күрә мин, әгәр гаепләре булса, олы актерларга да аңлатма язарга кушам. Чөнки актерларны зурга-кечкенәгә, яраткан-яратмаганга бүләргә ярамый. Андый бүленеш китсә, нәкъ менә төркемнәр барлыкка килә дә инде. Артист, гаделлек эзләп, синең яныңа керерлек булсын, каяндыр читтән аңлау эзләп йөрергә калмасын. Икәүдән-икәү сөйләшкәндә конфликтлы хәлне чишеп тә була. Әгәр инде артист үзен сөйкемсез сөяк итеп хис итсә, ул: «Мине барыбер якламаячаклар», – дип уйлый һәм эчке конфликтына чишелеш таба алмый. Шуңа күрә гадел булырга тырышырга кирәк. Дөньяда гаделлек болай да бик аз. Бу җәһәттән җитәкчегә аек акыллы ярдәмчеләр кирәк. Мин башка кешеләрнең фикерләренә колак салырга тырышам. Ник дигәндә, ярдәмче синнән күбрәк белә ала. Әгәр анарда бу сыйфат юк һәм ул гади башкаручы (йомышчы) гына икән, бернәрсә дә барып чыкмаячак. Артистларны да тыңларга, ишетә белергә кирәк. Әйтик, аның рольне башкарырга теләге юк икән, аны бу авырлыктан азат итәргә кирәк. Ә инде иҗади якларга килсәк, мин аларны санап китә алмыйм. Чөнки ул мактану була. Ә мактану – үзеңне хурлау инде ул.

:: Тинчуринда шушы ел ярым эчендә нәрсәләр үзгәрде?

– Ул хәзер төрле. Төрле режиссерлар, төрле пьесалар, төрле караш – миңа калса, болар барысы да театрны баетты. Мин бүген иҗат иткән язучылар, драматурглар белән эшләргә кирәк дигән фикердә. Әйтик, Ркаил Зәйдулла «Ашина»дан соң күпләргә яңа яктан ачылгандыр. Шамил Фәрхетдинов балалар һәм үсмерләр өчен пьесалар язды. Зөфәр Харисов тиздән спектакль чыгара. Мансур Гыйләҗев белән эшли башладык. Рабит абый Батулла кызыклы вакыйга сөйләде. Гомумән, Рабит абый – театр өчен бик күп эш башкарган кеше. Ул бу театрның режиссеры булган, драматург Кәрим Тинчурин шәхесен, иҗатын өйрәнгән, хатыны Заһидә ханымны соңгы көннәренәчә ярдәменнән ташламаган. Соңгы елларда театрга Тинчурин архивларын тапшырды, сүз белән дә, гамәл белән дә ярдәм итеп тора. Аның белән сөйләшеп утыру кызык. Бер әңгәмә вакытында бик гыйбрәтле вакыйга: Кәрим Тинчуринның ачлык елларында үз труппасы белән Урта Азиягә чыгып китүләре турында сөйләде. Менә шунда аларның вагоннарын чүл уртасында ычкындырып калдыралар. Һәм безнең көннәргә охшаш вакыйгалар башлана. Әгәр Рабит абый алынса, бу вакыйгадан безнең көннәр турында пьеса-аллегория килеп чыгар иде. Ә гомумән алганда, язучының әсәре сәхнәдә куелганда гына, аннан драматург чыга ала. Пьеса укыр өчен язылмый, аны куярга кирәк.

> Театрның эчтәлеге аның нинди чорда яшәвенә дә бәйле. Әйтик, совет заманында ул тәрбияви характерда булган. Ул вакытта сәнгатьнең әһәмиятен барысы да аңлаган. Хәзер исә театр күңел ачу формасына төште. Аннан «Камеди клаб» дәвамын көтәләр. Хәтта артистлар да, комедия кирәк, диләр... Бу очракта илдәге хәлгә карап эш итәргә кирәк. Барыбыз да бөтен нәрсәнең дә яхшы түгеллеген аңлыйбыз. Шуңа күрә театрда да караңгылык ясарга ярамый. Бу очракта проблемалы әсәрләр җиңел әсәрләр белән аралашып бара ала.

:: «Идегәй»дән нинди сабак алдың?

– Барыннан да бигрәк коллектив эчендәге хәлләргә нигезләнеп, билгеле бер нәтиҗәләр ясадым. Миңа төгәл картина булганда эшләү рәхәт. Әйтик, рус ТЮЗында эшләгәндә барысы да ачык иде: без сиңа каршы, диделәр һәм ул кешеләргә минималь нагрузка биреп, теләге булганнар белән эшләдек һәм бер-беребезгә комачау итмәдек. Монда хәл башкача: күзгә карап әйтү юк, ләкин без бу юнәлештә эшлибез. Ник дигәндә, эчке фетнәчелек эшкә дә, иҗатка да бик нык комачаулый. Кырын эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Бу анонимнар да ачылыр һәм аноним хат авторлары авыр хәлдә калыр. Дөрес, алар аз, әмма кайбер нәтиҗәләр ясауга этәргеч бирде.

:: Татар театрында русча фикерле торган режиссер эшли, дип тә әйттеләр синең хакта, килешәсеңме?

– Русча фикерле торган… Ул – ни дигән сүз соң? Мин теләсә нинди телдә куя алам. Ләкин… Әгәр чит ил классикасын, рус пьесаларын куйсам, без бары тик шулар аша гына дөнья театр мәйданына чыга алабыз дигән сәясәт алып барсам, русча фикерләү булыр иде. Рус театрлары репертуарын карагыз: хет берсендә татар пьесасы куеламы? Юк, чөнки аларда татарча фикерләмиләр. Әгәр без татар әсәрләренә генә алынабыз, хәзерге заман драматурглары белән эш йөртергә тырышабыз икән, моны татар мәдәниятен юкка чыгару дип атау – ахмаклык, миңа калса.

:: Бәлки сезнең куелышны аңламыйлардыр?

– Анысы да булырга мөмкин. Мәскәүдән Чаллы театрына кайтып, өч иң олпат актер белән эшләгән идем. Алар башка режиссерлар белән эшләгәндә, гадәттә, ярдәмчеләр булып китә, киңәш бирә, килешми, үзләренчә эшләргә тырыша. Ә миңа ләм-мим бер сүз эндәшмәделәр, ничек әйтсәм, шулай эшләп чыктылар. Соңыннан гына Булат абый: «Без Туфан ничек тели, шулай эшләсен, бер сүз дә әйтмибез, дип килешеп куйдык», – диде. Ышандылар һәм яхшы гына килеп чыкты. Түбән Кама театрында да ышандылар. Нәтиҗәдә, «Таң вакыты» спектакле белән «Алтын битлек»тә, Алма-Ата театраль фестивалендә катнаштылар. Үзгәрүдән, режиссерга ышанудан курыкмаска кирәк. Курыкмаганнарның эше күренә ул. Мәсәлән, яшь артистларның берсе Адилә Хәсәнова «Тантана» театраль премиясенә лаек булды.

:: Тинчурин театрының киләчәге нинди?

– Киләчәк турында кайгырту репертуарны яңартудан башлана. Кайбер спектакльләр китә, кайберләре килә. Кайвакыт соңгы елларда куелганнарның да гомере кыска була. Монда инде әсәрнең сәнгати әһәмиятенә һәм кассага ни дәрәҗәдә эшләвенә дә игътибар итәргә туры килә. Чөнки безгә андый таләп тә куела. Сүз уңаеннан, узган елда тамашачыга иң күп хезмәт күрсәткән театр – без икән. Әле күптән түгел генә бу хакта укыдым. Чыннан да шулай. Әйтик, бүген безнең ике спектакль белән районнарга чыгып киттеләр, кичкә стационарда уйныйбыз. Көнгә 3 спектакль күрсәтәбез булып чыга. Бу да – уңыш. Ә сәнгати яктан әһәмияте дигәндә, мин аны әсәрнең кешене уйларга мәҗбүр итүендә күрәм. Әгәр бер спектакль шушы ике таләпкә дә туры килсә, бу идеаль күренеш булып чыга. Әмма һәрвакыт алай була алмый, моны да аңларга кирәк.

:: «Әлиф», «Ван Гог», «Дәрдмәнд», Тинчурин театрында куелганнардан «Идегәй»... Болар барысы да – интеллектуаль тамашачы өчен куелган спектакльләр. Алар белән зал тутырып булмый, килешәсеңдер. Зал тутыру мәсьәләсен ничек хәл итәргә?

– Залны тутырып булмый, ләкин аларның нинди этәргеч биргәнен дә аңларга кирәк. Беренчедән, үзләрендә кузгатылган темага кызыксыну уяттылар, икенчедән, планка ролен үти башладылар. Әйтик, бер премьерадан соң, бу "Ван Гог" кебек килеп чыккан, дигәннәрен ишеткәнем бар. Димәк, шуңа тиңләшергә тырышу бар. Тарихта бит шундый спектакльләр кала. Чөнки алар милли сәнгати фикерләүне үстерәләр. Безнең бит совет вакытында фикерләү тарайганнан-тарайды. Байлар начар, муллалар начар, дигән карашны гасырлар буе сеңдереп килделәр. Дәрдмәнд тә бай булган, алтыннарын алып, чит илгә чыгып китмәгән бит. Яшьләрне Сорбоннада укыткан, мәчетләр төзеткән… Хәзерге байлар турында алай әйтеп булмый. Җыеп әйткәндә, тарлыктан котылырга, онытылган кыйммәтләрне искә төшерергә кирәк.

:: «Җилкәнсезләр» спектакле – чираттагы тәҗрибә. Интерактивны, пьесадагы башка үзгәрешләрне тамашачы ничек кабул итәр?

Блиц-сораштыру

– Соңгы укыган китап?
– Рэй Далионың «Принципы» китабы. Ул коллектив белән эшләү алымнары турында. Автор – Сбербанк президенты Герман Грефның укытучысы.
– Уңайлы яшәү мохите?
– Ирек булган урын. Мин монда эчке ирек турында әйтәм. Әйтик, «Әлиф» төркемендә мин иректә идем. Телеграм темага алындым, табыш турында уйламадым, вакыт ягыннан да иректә идем. Финанслау булмау да ирекле итә. Театр исә – системага салынган структура. Монда бик ирекле булып булмый.
– Мөмкинлек бирелсә, татар театры дөньясында нәрсәне үзгәртер идең?
– Фикерләүне. Татар халкы – дәүләтчелеге булган бөек халык. Безнең фикерләү дә җирләребез кебек үк киң булган. Әмма ниндидер бер вакытта халык кечкенә генә «гетто»га куып кертелгән һәм ул – хәзер безнең аңда. Менә шуннан арынасы, элеккеге иркен фикерләү рәвешенә кайтасы иде.
– Кешедә иң яратмаган сыйфат нәрсә?
– Икейөзлелек. Кеше сиңа ялган сөйли. Мин аның ялганлавын аңлыйм. Ул да минем аңлаганны аңлый. Ахмаклык инде бу. Менә шул – күңелгә иң тигәне.
– Кешене нәрсә бизи?
– Гадилек. Аллаһы Тәгалә дә катлауландырганны яратмый. Сүз уңаеннан, Тукайның иң гениаль әсәрләре – гади тел белән язылганнары. Пушкинда да шулай ук. Еш кына катлауландыру артында бушлык яшеренгән була.

– «Җилкәнсезләр» ул – үзе дә сәер әсәр. Бер яктан «Яшь гвардиячеләр»гә дә охшаган. Миңа калса, Кәрим Тинчурин 1926 елда үзе теләгән бар нәрсәне дә яза алмагандыр. Шуңа күрә аңа төп герой Батырханны да «яшерергә» туры килгән. Бер караганда, ул – аферистка охшаган, ә калебе белән драматик герой. Бу шул чорның тәэсире инде. Гаҗәеп чор бит: инкыйлаб, монархны бәреп төшерү, Дума оешу, аннары сугыш, аннары тагын инкыйлаб, коллективлаштыру, НЭП чоры, аннары НЭПны юкка чыгару һәм башкалар... Һәр иртәдә яңа илдә уянган кебек. Без дә шундый вазгыятьтә, әмма хәзер хәл тагын да глобальрәк. Без хәзер һәр иртәдә яңа дөньяда уянабыз. Кризислар, аңа кадәр пандемия, хәзер нейрочелтәрләр килеп чыкты, аның белән дә куркыталар. Глобаль шикләнү чорында яшибез кебек. Бернәрсәгә дә ышанып булмый бит. Акча яна, шәхси мәгълүмат урлана, кыскасы, ышанмау кризисы барлыкка килә. «Җилкәнсезләр»дә шул ук хәл. Анда Мисбах Батырханга ышанмый һәм башкалар. Геройлар нинди саламга ябышырга белми. Үз комитетларын төзеп карыйлар, алар эшләп китә алмый... Алар да глобаль билгесезлектә яши. 1905 елдан 1926 елга кадәр никадәр үзгәреш. Әйе, без аны яңача куеп карыйбыз. Ә тәнкыйть – бик әйбәт нәрсә ул. Мин аннан курыкмыйм.

:: Тәнкыйть кешене сындыра аламы?
– Мине сындыра алмый. Ә гомумән алсак, Татарстанда күпләрне сындырган инде ул. Кеше ризалаша, болай эшләсәм, мине аңламаслар, дип үз фикереннән кире кайта икән, ул инде сынган. Андый хәлгә төшмәс өчен, үзеңнең теләсә кайсы вакытта китә алуыңны аңларга кирәк. Мин теләсә кайсы вакытта китә алам. Эш була ул. Шуңа күрә ТЮЗдан да курыкмыйча киттем. Анда иҗади күтәрелеш, әмма үзем өчен башка үсеш булмаячагы да аңлашыла иде. Шуңа күрә саубуллашу спектаклен куйдым да киттем. Аны барысы да аңлады. Тинчурин театрында әле эшлисе эшләр шактый.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РӘШИТ ФӘТХРАХМАНОВ

САКЛАУЧЫ ФӘРЕШТӘ

(ХИКӘЯ)

Хәлим Шәйдуллин, бүген эшкә барганда, тагын истәлекләргә чумып, ачы сагыш кичерде. Инженерлык механикасы һәм гамәли математика кафедрасы мөдире ул. Күптән түгел генә академик итеп сайланды. Гаиләсе бар, байлыгы да җитәрлек. Аның таланты һәм аның белгечлеге белән акча табу кыен түгел бу заманда. Илле биш яшь кенә әле үзенә. Чәчләренә чал да кермәгән, чем-кара. Каратут йөзле урта яшьләрдәге ирне күрсә, хатын-кызларның күбесе әле дә һушын югалта. Гүзәл затларга үзенең тылсымлы тәэсире барлыгын яшьтән үк сизә иде Хәлим, әмма бер тапкыр да моннан явызларча файдаланмады. Тик шулай да йөрәген телә торган бер сере бар аның. Сызлата торган сере, кешегә сөйләп йөреп булмый торганы.

Кая гына барса да, ни белән генә шөгыльләнсә дә, күңелдән китми торган исемне еш кабатлый ул. «Их, Гөлзәйнәп, кайларда гына йөрисең икән син, кайларда гына?!» – дип, күңеленнән томаннар артында еракта калган түгәрәк йөзле, кәлгәндә битендә мәхәббәт чокырлары батып китә торган кыз белән сөйләшә. Еракта дигәч тә, томаннар артында дигәч тә, барысы да кичә генә булган кебек. Гомер кыска шул, бик тиз үтеп китә. Яшәп туярга да өлгермисең, кай арада яшең иллегә җитә, алтмышка да кул сузымы гына кала.

Менә шулай уфтанып яши Хәлим Җәүдәт улы, Мәскәү академигы. Их, барысын да ташлап, дан-дәрәҗәсенә төкереп, башкала үзәгендәге дүрт бүлмәле затлы фатирга кул селтәп, Казанның яшьлектәге тулай торагының бер бүлмәсенә кайтып булса икән. Юк, күпкә түгел, бер генә төнгә. Менә шул яшьлекнең бер төненә, бер таңына кайтса, тәкъдирне бөтенләй башка сукмакка борыр иде ир. Әйтик, аның Мәскәүдәге фатирын сатсаң, миллион доллардан артык бирәчәкләр. Шул байлыкның тиенен дә кызганмыйча, яшьлекнең бер төнлегенә алыштырыр иде. Тәкъдирләр сатылмый шул, язмышлар бер генә вариантта языла.

Эшкә килеп, кафедра мөдиренең затлы кәнәфиенә чумган гына иде, телефон шалтырады. Александров Владимир Васильевич икән. «Добрый день, Халим Зяудатович!» – дип эндәшүгә таныды ул МГТУ профессорын. Ике галим бер-берсен бик хөрмәт итәләр. Үтенеч-гозерләрен бер дә аяк астына салып таптамыйлар. Бу юлы Владимир Васильевич үзенең бик талантлы аспирантына Хәлим Җәүдәт улының оппонент булуын үтенә икән. Сезнең кавемнән, бик талантлы егет, дигән сүзләрдән соң: «Отчего-то он мне напоминает Вас», – диде Васильев. Оппонентлык бик мәшәкатьле хезмәт булса да, профессорның үтенечен кире кага алмый иде Хәлим. Ул аның остазы иде. «Татар егете, Сезне хәтерләтә», – дигән сүзләр булмаса да, кире какмас иде. Тиз килеште. Васильев Хәлимнең электрон почтасына егетнең автореферат кулъязмасын җибәргән икән, танышуны үтенде.

Вакыты бар иде, академик ашыкмыйча гына почтаны ачты. Авторефератның титул битенә «Иштиряков Азат» дигән исем язылган иде, отчествосы ни өчендер юк. Фамилияне күрүгә, Хәлим дерт итеп китте, чак кына кәнәфидән егылып төшмәде. Иштиряков фамилиясе сирәк очрый һәм ул инде утыз елдан артык Хәлимнең үзәген өзгән Гөлзәйнәпнең фамилиясе иде. Ир нидер сизенде, профессорның: «Сезне хәтерләтә», – дигән сүзләре башка чүкеч булып сукты, мигә шаулап кан йөгерде. Каушап, фәнни хезмәтнең темасын укыды. Катлаулы тема, фәндә яңа адым. Андый темага йөрәкләнеп теләсә кем тотынмый. Хәлим тиз генә интернетның эзләү системасына егетнең исем-фамилиясен язды. МГТУның гамәли математика кафедрасы хезмәткәрләре арасында аның турында да мәгълүмат бар икән. Галим мәгълүматны укып тормады, егетнең фотосына карады да катты. Фотодан аңа яшьлеге карап тора иде.

...Фәнни җитәкчесе сөйләшкәнен әйткәч, Азат академик Шәйдуллин янына барырга җыена башлады. Диссертациясе бик уңышлы килеп чыкты аның. Васильев әйтүенчә, докторлык диссертациясенә тиң икән. Кафедрада тикшергәндә, барлык галимнәр дә беравыздан шунда ук докторлыкка тәкъдим итүне куәтләделәр. Кандидатлыкны якламый гына, шунда ук докторлыкка сикерү – сирәк була торган хәл. Азат бит бер тәрәксез күтәрелде бу тормышта. Әтисен бөтенләй белми, әнисе күптән, Азатка җиде яшь тулганда ук вафат булды. Шуннан балалар йортында михнәтле тормыш башланды. Кыерсытылулар, изелүләр чоры. Ул йорттан чыгуга, ятимнәрнең күбесе шуңа күрә тормыш төбенә тәгәриләр.

Әнине сагыну хисе дә йөрәккә авырлык өсти иде. Әтисе турында хыяллар белән юанырга тырышып карады. Кайчан да булса бер ул килеп чыгар да бу газаплы тормыштан коткарыр кебек тоела иде. Хыял белән юанырга тырышу гына иде бу. Әтисе турында сорагач, әнисе гел бер сүз генә әйтә иде: «Үскәч, сөйләрмен». Соңрак, бераз үсә төшкәч, малай үз документларында отчествосы юклыкка игътибар итте. Тыйнак һәм саф күңелле әнисе шулай зинадан бала таптымы икәнни? Моңа ышанасы килми иде. Ирләр белән бер дә аралашмый иде аның әнисе. Улын иркәләп тә карады соң! Әниле татлы чор озак булмады шул, бер төш кебек кенә хәтердә калды.

Балалар йортында өч ел яшәгәннән соң, җәйнең бер матур көнендә Азат качты. Туган авылы Акчураның кайсы якта икәнен чамалый иде. «Әнинең йортына кайтам да шунда үзем яшим» дигән уй күңелен тәмам биләп алды. Матур бер иртәдә ул китте күңеле тарткан тарафка. Ул көннең һәр мизгелен хәтерли егет, һәр адымы истә. Олы юл буйлап вак адымнар белән байтак атлагач, ашыйсы килә башлады. Ашарга берни дә алмаган иде. Акчурага таба юлаучы машиналар да сирәк үтә. Үткәне дә туктамады. Ачлыкка чыдый алмыйча, юл читендә җиләк җыеп ашый башлады. Җиләк мул иде, кып-кызыл иде. Учлап-учлап тутырды авызына. Юлдан читкә китүен дә аңышмый калды. Су эчәсе килә башлады. Якындагы кечкенә күлне күреп, шунда китте. Дөнья күрмәгән бала каян белсен, күл дигәне сазлык булып чыкты. Ялгыш бер адым ясавы булды, сазлыкка барып төште. Сазлыкның кешене ничек суыруын киноларда күргәне бар иде аның. Хәзер шул дәһшәтне үз тәне белән татый. Салкын лайла күкрәкне кыса, акрын гына аска таба тарта. Йөрәкне тәмам курку-каушау биләп алды. Ачыргаланып: «Әни!» – дип кычкыруы бала һәм кинәт күл читендә әнисен күргәндәй булды. Юк, чынлап та күрде ул аны. Хатын малайга тутырып бер карады да кинәт юкка чыкты.

Азат белми иде: олы юлдан иске бер «Жигули» үтеп бара. Көтмәгәндә аның юлына ап-ак күлмәкле хатын чыгып колачын җәеп басты. Автомобиль туктамыйча булдыра алмады. Ашыкмый гына ишекне ачып төшкән шоферга хатын: «Анда, сазлыкта, минем улым бата. Аллаһ хакы өчен коткарыгыз аны», – дип инәлеп эндәште. Бу юлы шофер озак көттермәде. Тиз генә багажниктан бау алды да хатын күрсәткән якка ыргылды.

Сулышы кабып, Сәләхетдин абый килеп җиткәндә, сазлык Азатны иягенә кадәр үзенә суырып килә иде инде. Әле ярый, нәрсәгәдер тотынырга теләп, куллары өскә күтәреп кала алды. Ыргытылган бауга ябышып, ярга чыгу бер дә җиңел булмады. Ир, ике аягын җиргә терәп, тиргә батып тартуга карамастан, сазлыкның малайны бер дә җибәрәсе килмәде. Икәүләп тырыша торгач, коры җиргә чыгып егылынды тагын. Абзый кеше, маңгаендагы тирен сөртеп, киң итеп елмайды:

– Бәхетең бар икән, – диде. – Әниең шатланыр инде.

Әнисе исенә төшеп, малайның үзәге өзелеп китте. Әни! Чынлап та, менә шушы урында әнисе басып тора иде бит аның. Үз күзенә үзең ышанмассың. Азат галлюцинациянең ни икәнен белә. Китапларны күп укый ул. Алар аның бердәнбер юанычына әйләнделәр. Димәк, әни күзгә генә күренгән.

– Әнием өч ел элек үлде бит минем, абый, – диде ул, еламсырап.

– Тукта, ничек? Ә мине кем туктатты соң?

Коткаручы ир, гаҗәпләнеп, маңгаен сөртте. Колагында: «Анда, сазлыкта, минем улым бата. Аллаһ хакы өчен коткарыгыз аны», – дигән сүзләр кабат яңгыраган төсле булды. Хатынның бөтен йөзе, күзенә-кашына кадәр хәтеренә сеңгән иде аның. Бик чын иде барысы да. Шул хатын туктатмаса, Сәләхетдин баланың сазлыкка батып ятуын каян белсен! Ана коткаручы артыннан улы янына чабарга тиеш иде. Бәлки, әле узып та чабарга. Әмма юлга кадәр сукмак буш. Әнә күктә тургай сайрый, анысы хак. Тирә-юньдә башка бер җан иясенең дә барлыгы сизелми. Сәләхетдин, уйга калып, бөтен тирә-юньне күзе белән айкап чыкты.

– Абый, ә үлгәннәр терелеп кайта алалармыни соң?

– Юк, энем, юк. Кайта алмыйлар. Барзахтан киргә таба юл юк.

Баланың күзләрендәге сүзсез сорауны күреп өстәде:

– Сине Аллаһы Тәгалә саклаучы фәрештәсен җибәреп коткарган, димәк. Фәрештәләр теләсә кайсы кеше кыяфәтенә керә алалар.

Саклаучы фәрештә! Аның янәшәдә булуын гел тоеп яшәде шуннан соң Азат. Авырлыклар аша үтү җиңелләште. Теге чакта Сәләхетдин абыйсы аны үз янына алып кайтты. Тормышын сөйләтте, зарларын тыңлады. Ир юкка чыгып баручы авылда ялгызы яши икән.

– Акчурага юл бик ерак бит, энем, – диде ул. Анда җәяүләп кайтып җитә алмассың. Поездга утырырга кирәк, аннан соң тагын автобус, я юлаучы машинага күчәргә. Булганым бар минем ул Акчурарда синең. Мәктәпсез, кибетсез бер авыл. Сиңа укырга кирәк, үсәргә.

– Детдомда яши алмыйм мин, абый, яши алмыйм, – дип үкседе Азат. – Әтием дә юк бит ичмасам.

Сәләхетдин абый бик озак уйга батып торды.

– Да, – диде ул, уйчан гына. – Әтисез кеше булмый ул. Кайдадыр бар синең әтиең. Бик зур табышмак бит әле бу. Югыйсә, сөйләвеңә караганда, әниең бик акыллы кеше булган. Әтиең белән юллары ник аерылышты икән соң?

Ахыры бар >

НИЧЕК ТИЗ ГЕНӘ ЙОКЫГА КИТӘРГӘ

Уены-чыны бергә

- Тәрәзәне ачып, бүлмәнең һавасын алыштырырга.
- Урын җәеп, түшәккә ятарга.
- Иртәгәге көнгә планнар кора башларга.
- Бүген башкарырга өлгермәгән эшләр өчен үкенергә.
- Ашыйсы килгәнен сизеп, суыткыч янына чыгарга.
- Ашарга күңелсез булмасын өчен, берәр документаль фильм кабызырга.

Әз-мәз мәзәк

– Аның 10 мең хезмәткәре бар диләр, дөресме?
– Дөп-дөрес. Умартачы ул.

* * *

«Сольный» концертка халык әз килсә, ул «малосольный» санала.

* * *

– Ә син акчаңны кайда саклыйсың?
– Хатирәләремдә.

Бездә берни югалмый! Кайвакыт таба гына алмыйбыз.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Гөберчәк, Итле, бет, миләш, нисаб, Ла, Рабит, Бали, ефәк, Буратино, Уел, ямау, халәт, па, шыр, ындыр, Мезим, яхшы, ИНН, ни, Вамин, Рейн, Атос, Ирек, аһәң, Наил, бу, җелек, ару, Вучич, ялагайлану, чәукә.

Вертикаль: Газинур, япон, Ислямия, алма, ияр, Ибушев, Ту, ызан, Рим, әрмән, Бах, Минһаҗев, Ихата, иләс, Лилия, аң, лачын, Алинә, хат, Бери, Тошиба, отыш, укучы, Нырсы, Форд, йон, Куприн, би, Тәхвәтуллина, Ләйсәнә.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК

ФИНИШ БРОЙЛЕРЫ өчен

(26 көнлек һәм аннан зуррак бройлерлар өчен)

КАТНАШ АЗЫК

Глазов һәм Богданович шәһәрләре заводларында җитештерелгән терлек азыгын (бройлерлар, йомырка салучы тавыклар, бытбылдыклар, йорт куяннары, мөгезле эре терлек, куркалар өчен), шулай ук арпылмаган сөтне иртыручы рызык, мөгезле эре терлек өчен тоз һ.б. сайлап алу мөмкинлеге зур.

Казан, Техническая урамы, 15. тел.: +792-704-99-706

Чаллы, Магистральная урамы, 1а/1. тел.: +792-767-27-366

сыер рәсеме төшерелгән сары баннерны эзләгез!

Безнең сайт: agroline1.ru

реклама

Сканворд

Мәһдиев авылы
...-миләс
Этчаба дип ул чаба
Ереванда яши
Казанда татар рестораны
Зөлфия Минһаҗева агачы
«Җырлыйк әле» алып бара
Зәкят исәпләү мөлкәте
...Манш
Батулла
Индонезия утравы
Япон телевизоры
Югла исем биргән тукыма
Кием тишеген каплагыч
..., пеш, авызыма төш!
Балачак лимонады
Машина төзүче Генри ...
Очкыч
Хәзерге хәл
Жирлек
Италия каласы
Лотерея әҗере
... табагы
Татар халык җыры
Био элементы
Илназ ...
... ялангач
Койма белән урап алынган
Винарис хатыны
Сәлим туләүче номеры
Ашказаны дәруы
Вагыйз Минһаҗев
Әйбәт, хуп
Әби әрли
Кисәкчә
...-белем
Mail
Морза
Токиода яши
Ат җайланмасы
Җырчы Георгий ...
Моңлы яңгыраш
Портос дусты
Алман елгасы
Рус язучысы
ТНВдан Садретдинова
Казандагы мәчет
Британ футбол клубы
«Икеле» капчыгы
Теләче районы авылы
Аны суырлар
Самавыр пары
Керәшен «яхшы»сы
Җырлар авторы Айдар ...
Ертыкч кош
Сербия Президенты
Артык ярарга тырышу
...-чыпчык, тәрәзәдән очып чык



Беләсең килсә...

1 Корьәндә мәчет ничә тапкыр искә алына?
а) 17;
б) 28;
в) 40.

2 Язучы Сэмюэль Лэнгхорн Клеменс безгә нинди тәхәллүс аша таныш?
а) Джек Лондон;
б) Даниель Дефо;
в) Марк Твен.

3 Даниядә нинди акча йөрештә?
а) фунт;
б) крона;
в) доллар.

4 «Теннис» француз сүзеннән чыккан. Ул нинди фигыльне аңлата?
а) тотыгыз;
б) уйнагыз;
в) җиңегез.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 249

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+